**1 класс. Татар теле. Аңлатма язуы.**

.

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасы законы (гамәлдәге редакция) (- Закона РФ и РТ «Об образовании»

2.Россия Федерациясенең телләр турындагы законы (№126-ФЗ 24.07.1998)

3.ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 нче ел 9 нчы июль 4154 /12 номерлы “ТР гомуми һәм төп белем бирү оешмалары өчен базис һәм үрнәк укыту планнарын раслау турындагы” карары

4.Сан ПиН 2.4.2.2821-10. “Гомумбелем бирү оешмаларында укытуга карата санитар-эпидемиологик таләпләр” (РФ төп дәүләт санитар табибы карары белән 2010 нчы елның 29 нчы декабрендә расланган. РФ Юстиция Министрлыгы тарафыннан 2011 нче елның 3 нче марты 189 номеры белән теркәлгән, теркәлү номеры - 19993)

5. Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. (Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В.Х.Хаков, Г.Г.Измайлова, Э.Х.Хәмидуллина – Казан, 2008).

6. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы” (татар балалары өчен)Төзүче авторлары Ф.Ф.Харисова, Ч.М.Харисова, В.А.Гарипова - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел

7.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы”4нче санлы Урыссу гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2014-2015уку елы өчен укыту планы

8. Дәреслек: 1) Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

2) Ф.Ф.Харисов, Г.Д.Сиражиева.Татар теле: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар”буенча 1 нче сыйныфлар өчен татар телен укытуга 102 сәгать каралган. Мәктәпнең еллык календарь укыту графигы буенча 1 нче сыйныфларда 33 атна булу сәбәпле, эш программасы белем бирү учреждениесенең гамәлдәге базис планы буенча атнага 3 сәгать исәбеннән 99 сәгатькә төзелә. Эш программасында, барлык өйрәнелә торган темалар сакланып, сәгатьләр санына үзгәрешләр кертелде. Бу үзгәрешләр программаның эчтәлегендә күрсәтелә. 1 нче сыйныф өчен әзерләнгән эш программасының эчтәлеген мәктәптә үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр тәшкил итә

**Татар теленнән белем бирү максатлары:**

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнүгә теләк уяту, үз милләтеңә, татар теленә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
2. Балаларда татар теленнән мәгълүматлылык булдыру:

- татар телендә аралашу күнекмәләре формалаштыру;
- тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә өйрәтү;
- тел белеменең фонетика, лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү күнекмәләрен булдыру;
- сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
- укучыларда татар теленә карата хөрмәт хисе һәм ихтирам тәрбияләү,телнең чисталыгын,дөреслеген саклап, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

3. Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълүмат булдыру.Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча әйткәнне аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә ,аерым темаларга әңгәмәләр кора белергә,аралашканда , тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре формалаштыру.
5. Укучыларда татар этнокультура мәгълүматлылыгын үстерү.
6. **Төп бурычлар:**

- Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту.
- Балаларда татар теленең барлык тармаклары буенча компетенцияне булдыру.
- Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълүматлылыкны булдыру.
- Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

1 нче сыйныфта укучылар аваз һәм хәрефне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль кебек сүз төркемнәре турында башлангыч мәгълүмат алалар. Сөйләм берәмлеге буларак җөмлә, аларны төрле интонация белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән хикәяләр төзи белү күнекмәләре дә бирү әһәмиятле. Укучыларның татар телен белү дәрәҗәсен исәпкә алып, укытучы дәресләрдә татар һәм рус теле үзенчәлекләренә тукталырга, тәрҗемә өлкәсенә караган биремнәр дә тәкъдим итәргә тиеш.

Программада һәр сыйныфта бәйләнешле сөйләм үстерү өчен, аерым эш төрләре һәм темалар тәкъдим ителә. Сөйләм телен үстерү уку дәресләрендә дә дәвам иттерелә. Татар теле дәресләрендә укытучы халык авыз иҗаты үрнәкләреннән дә файдалана. Табышмаклар, әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәрләргә матур язу да балаларны әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора.

**1 нче сыйныф укучыларының татар теленнән белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

1. “Телдән әзерлек чоры” өчен тәкъдим ителгән темалар буенча бирелгән сүзләрне аңлап, кара-каршы һәм монологик сөйләмдә куллана белергә тиешләр.
2. Хәрефләрдән иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү. Сүз басымын дөрес куеп уку.

3. Татар теленең үзенчәлекле сузык һәм тартык авазларын дөрес әйтү, бу авазларны белдергән хәрефләр булган сүзләрне язу. Татар теленең үзенчәлекле авазлары кергән сүзләрдәге аваз һәм хәрефләрне аерып әйтә белү.
4. Җөмләләрдән исем, фигыль, сыйфатларны табу. Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен аңлату. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.

**1 нчесыйныф (татар төркеме) өчен татар теленнән программа эчтәлеге**

| № | Бүлекләр | Сәгать саны | Темага караган төп төшенчәләр. |
|---|---|---|---|
| **I.** | **Телдән әзерлек чоры** | **32** | |
| 1 | Танышу | 2 | Малай, кыз, исемем, исеме, мин, син, рәхмәт, бар, исәнмесез, исәнме, сәлам, сау булыгыз, бу, кем, ничек, ничә, алты, җиде. Син кем? Исемеңничек? Ул кем? Аныңисеменичек? төзелмәләре.<br>-мы/-ме? кисәкчәләре.әйе,юк, түгел сүзләре. Зат алмашлыклары.<br>БСҮ “Танышу” |
| 2 | Безнең мәктәп (сыйныф) | 5 | Мәктәп, сыйныф, тәрәзә, укый, яза, җырлый, ясый, бирә, керә, ишек, дәрес, зур, кечкенә. Уку-язу әсбаплары.Нәрсә? соравы. Зат алмашлыкларын кулланып,предметның кемгә караганлыгын белдерү.Нинди? Кайсы? сораулары.Предмет-ның билгесен белдерүче сүзләр.<br>БСҮ “Безнң мәктәп(сыйныф)” |
| 3 | Безнең гаилә | 4 | Гаилә, әти, әни, апа, сатучы, өстәл, төзүче, урындык, йоклый, ял итә,бүген, иртәгә, тугыз, ун, шәфкать туташы.Предметның саны,билгесе, урыны турында хәбәр итү.<br>БСҮ “Безнең гаилә” |
| 4 | Ашамлыклар | 2 | Аш, ботка, токмач, икмәк, катык, пешерә, кыздыра, кисә, бүлә, чәйнек, эчә, тәмле, булыша.Белән бәйлеге+фигыль тезмәсен дөрес куллану.<br>БСҮ “Ашамлыклар” |
| 5 | Кеше | 3 | Кеше, теш, борын, колак, чәч, сөртә, чиста, юына, сөлге, сабын, юа, уң, сул, чиста, пычрак.Шәхси гигиенага караган эш-хәрәкәт,бу эш-хәрәкәтнең үтәүчесе турында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | хәбәр итү.<br>БСҮ “Кеше” |
| 6 | Өс-баш һәм аяк киемнәре | 3 | Күлмәк, яулык, чалбар, бияләй, итек, иске, кара, зәңгәр, чишенә, элә, бәйли, тегә. өс-баш һәм аяк киемнәренең аталышы. Кемнеке? соравы.<br>Предметның билгесен белдерүче сүзләр .Нинди? соравы.<br>БСҮ “Өс-баш һәм аяк киемнәре” |
| 7 | Уеннар | 2 | Чана, чаңгы, тимераяк, туп, шар, уен, тора, матур, җилле, тайгак, йомшак, каты.Предметның саны, урыны турында хәбәр итү.<br>БСҮ “Уеннар” |
| 8 | Авылда | 3 | Авыл, урман, бакча, чия, алма, кәбестә, көрән, сыер, ат, сарык, тавык, керпе, эт, төлке, куян, үрдәк, утырта, оча, йөгерә, кызыл, яшел, бүре, аю, керпе, кыяр, бәрәңге, кишер, суган, көрәк.Кыргый һәм йорт хайваннарының яшәү урыны турында хәбәр итү. Яшелчә һәм җиләк-җимешнең үсү урыны турында хәбәр итү.<br>БСҮ “Авылда” |
| 9 | Кошлар | 2 | Чыпчык, сыерчык оясы, бөркет, сандугач, саескан, тургай, кош оясы, очып кайта, җим, кара карга, бөркет, тургай, җимлек, карабүрек, күке, торна, песнәк.Күчмә һәм кышлаучы кошлар турында сөйләү.<br>БСҮ “Кошлар” |
| 10 | Шәһәрдә | 3 | Шәһәр, урам, тукталыш, туктап тора, кайта, яши, киң, тар, тиз, акрын, һәм.Предметларның билгеләре турында хәбәр итү. Эш-хәрәкәтнең билгесен белдерү.<br>БСҮ “Шәһәрдә” |
| 11 | Бәйрәмнәр | 3 | Туган көн, Яңа ел, Корбан бәйрәме, котлый, елмая, кунак итә, ярыша, колга, кадерле, бәхетле, мәчет, күчтәнәч, ихтирам итә.Бәйрәмнәрне санап күрсәтү. Милли бәйрәм-Сабан туе турында сөйләү.Бәйрәм белән котлау.<br>БСҮ “Бәйрәмнәр” |
| **II.** | **Әлифба чоры** | **47** | Хәреф, авазларны өйрәнү, татар теленә хас авазлары дөрес әйтү, алар кергән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сүзләрне, сүзтезмәләр һәм җөмләләрне дөрес уку.<br>1.Сүзлек диктанты  “Сузык [ө] авазы. Ө,ө хәрефләре”<br>2**.**Сүзлек диктанты [й] авазы. Й,й хәрефләре”<br>3.Сүзлек диктанты “Сузык Е,е хәрефләренең [йы],[йэ] авазларын белдерүе”<br>4. Сүзлек диктанты “В,в хәрефләре. Ирен-ирен [w]һәм[в] авазлары”.<br>5..Күчереп язу “Иртән”<br>6.Диктант “Кошлар килә” |
| **III.** | **Грамматика** | **20** | Җөмлә турында гомуми мәгълүмат, сүзләр арасында бәйләнеш. Дөрес язу һәм сөйләү күнекмәләре булдыру.<br>Калын һәм нечкә сузыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы, яңгырау, саңгырау тартыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.<br>Сүзләр иҗекләргә бүленүе, иҗек сузык аваз ярдәмендә төзелүе.<br>Кеше исемнәре, фамилияләр, шәһәр, авыл, елга исемнәре, хайван кушаматларының баш хәреф белән язылуы.Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре.<br>Сузык һәм тартык аваз хәрефләрнен дөрес язылышы<br>Сүз басымын дөрес кую, сузык авазга төшүе.<br>Исем, мәгънәсе, уртаклык, ялгызлык исемнәрнең язылышындагы үзенчәлек.<br>Фигыль, барлык-юклык формалары турында төшенчә.<br>Сыйфат, мәгънәсе, сораулары.<br>1.Күчереп язу “Татарстан”<br>2.Диктант “Май ае” |
| | **Барлыгы** | **99** | |

**Универсаль уку  күнекмәләре.**

Татар теле  буенча төзелгән эш программасы 1 нче  сыйныф укучыларының шәхси үсеш-үзгәреш, предметара һәм предмет нәтиҗәләрен үзләштерүне күз алдында тота.

**Шәхси үсеш-үзгәреш нәтиҗәләре:**

1.Уңай мотив тудыру. Уку теләге булдыру,  мәктәп һәм уку эшчәнлеге турында уңай күзаллау булдыру.Мәктәпкә уңай мөнәсәбәтле укучы карашы формалаштыру..
2.Яхшы укучы образын кабул итү, яхшы укучы булу теләге тудыру.
3.Үз фикереңне җиткерү.Үз фикереңне яклый, дәлилли белү. башкаларны тыңлый белү, иптәшләрең фикере белән исәпләшү. Кеше фикеренә карата ихтирамлы караш булдыру. Кеше чыгышына игътибарлы булу.
4.Үз гаиләңә карата уңай караш, ихтирам тәрбияләү. Туганлык кыйммәте формалаштыру.
4.Тәрбияле бала образын кабул итү.Әхлак нормаларын үзләштерү.Әхлакый сыйфатлр формалаштыру.
5. Туган якка мәхәббәт хисе формалашу. Үзеңнең этник катламга мөнәсәбәтле булуыңны аңлау. Милләтнең, Ватанның бер вәкиле булуың белән горурлану.Милли үзаң булдыру. Толерантлык хисе булдыру.Горурлык һәм гражданлык хисләре формалаштыру.
6.Сәламәт яшәү рәвешен, ярдәмчел бала образын кабул итү.
7. Үзбәяләү.Уңышлы уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә үзбәя.

**Предметара нәтиҗәләр** булып универсаль уку гамәлләре формалашу  санала. Грамотага өйрәтү курсын үзләштергәндә формалашучы универсаль уку  гамәлләре: регулятив универсаль уку гамәлләре , танып-белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәлләре.

**Предметара нәтиҗәләр:**

1.Дәреслек битләрендә ориентлашу. Уку мәсьәләсен куя белү,аңлау һәм үтәү.Уку хезмәтенә максат кабул итү, аңа ирешү өчен этапара бурычлар кую. Укытучы бәяләвен уңай кабул итү,үзэшчәнлекне планлаштыру. Төрле ситуациядән чыгу юлларын табу.Уку эшчәнлеген оештыру.
2.Эстетик һәм рухи кыйммәтләр тупларга омтылу. Тиешле мәгълүматны таба белү.Тамга-символлик уку гамәлләрен үзләштерү.
3.Сорау кую һәм аларга җавап бирү; аралашу-сөйләм эшчәнлеген формалаштыра белү; тирә-яктагылар белән аралашу ысулларын үзләштерү, иптәшләрең  белән хезмәттәшлек итү, күршеңне тыңлый белү.Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. Сөйләмдә итагатьле сүзләр куллану, үз фикереңне формалаштыру һәм дәлилли белү. Мәгълүмат белән эшләү культурасын формалаштыру.Дөрес һәм аңлап уку күнекмәләре булдыру.
**Регулятив универсаль уку гамәлләрен**формалаштыру чарасы булып, продуктив уку технологиясе; , **танып-белү универсаль уку гамәлләрен**  формалаштыру чарасы булып, дәреслектәге текстлар, беренчел мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен тәэмин итүче методик аппарат; **коммуникатив универсаль уку гамәлләрен**  формалаштыру чарасы булып, продуктив уку технологиясе һәм эшне парлап, кечкенә төркемнәрдә оештыру тора.

**Предмет нәтиҗәләре:**

1.Дәреслек белән дөрес эшләргә , укыганда дөрес утыру кагыйдәләрен үтәргә өйрәнү.”Әйтмә” һәм “язма” сөйләмне аерырга, сөйләм этикеты нормаларына өйрәнү.
2.Сүз һәм җөмлә, аваз һәм хәреф аермасын аңларга өйрәнү.Авазларны дөрес әйтергә, хәрефләрне дөрес язарга өйрәнү. Орфоэпик дөрес, аңлап һәм сәнгатьле итеп укырга , куелган тема буенча үз фикереңне әйтергә өйрәнү.

3.Калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны чагыштыра һәм аера белергә, сүзгә фонетик анализ ясарга өйрәнү.
4.Предметны , предметның билгесен һәм хәрәкәтен белдерүче сүзләрне аерып таный белү  һәм сөйләмдә дөрес куллану.

**Мәгълүмат һәм белем  бирү чыганаклары**

| УМК | Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|---|
| 1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт  ителгән  “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар”1-11 нче сыйныфлар. – Казан: Татарстан, 2011.<br>2.  Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, “Мәгариф” нәшрияты, Казан, 2008.<br><br>3. Дәреслек:<br>1) Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.<br>2) Ф.Ф.Харисов, Г.Д.Сираҗиева.Татар теле:  Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012. | 1. Исмәгыйлева С. Г. Рус мәктәпләрендә белем алучы татар балаларына ана телен һәм әдәбиятын укыту. – Казан: Мәгариф, 1993.<br>2. Ягъфәров Р. Г. Кәҗә-мәкәрҗә. – Казан: Мәгариф, 1994.<br>3.Ягъфәров Р. Г. Татар балалар фольклоры. – Казан: Раннур, 1999.<br>4.Харисов Ф. Ф., Харисова Л. А. Уен – милли тәрбия чарасы. – Чаллы: КамАз, 1994.<br>5.Гөлбакча, балалар өчен хрестоматия. - Казан: Татарстан китап нәшрияты,1990;<br>6. «Фән һәм мәктәп», «Мәгариф» журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары<br>7. http://www.tatmedia.com<br>8. http://www.tatar.ru<br>9. http://www.selet.biz/<br>10. http://www.tatar.com.ru<br>11.Вәгыйзов С. Г., Вәлитова Р. Г. Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2001.<br>12.Сафиуллина Ф. С., Ибраһимов Г. Б. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел. – Казан: Мәгариф, 998.<br>13.Багаева Җ. З. Татар теленнән | 1. Дәреслек<br>1) Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.<br>2) Ф.Ф.Харисов, Г.Д.Сираҗиева.Татар теле:  Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.<br>2. Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Язу дәфтәре: Рус телендә башлангыч гомуми  белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен язу дәфтәре( татар телендә сөйләшүче балалар өчен)2 кисәктә.. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.<br>3. Ягъфәров Р. Г. Кәҗә-мәкәрҗә. – Казан: Мәгариф, 1994.<br>4.“Көмеш кыңгырау”,“Сабантуй” газеталары<br>5. Нәниләргә бүләккә. Җыентык. Табышмаклар, такмаклар, әкиятләр, шигырьләр, кыска хикәяләр. – Казан: Тат. кит. нәшр.. |

| | | |
|---|---|---|
| 4. Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Язу дәфтәре: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен язу дәфтәре( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) 2 кисәктә.. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012. | грамматик биремнәр (башлангыч мәктәп өчен). – Яр Чаллы, 2002.<br>14.Татар теленнән диктантлар. – 1-4 сыйныфлар өчен. – Казан: Мәгариф, 2006. | 6.Орфографик, орфоэпик һәм башка төр сүзлекләр. |

**Сәгатьләр бүленеше**

| Предмет | Сыйныф | Барлык сәгатьләр саны | Атнага сәгатьләр саны | Өйрәтү характерындагы язма эшләр | | | БСҮ дәресләре саны | Дәреслекнең авторы, елы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Күчереп язу | Сүзлек диктанты | Диктант | | |
| Татар теле | 1 | 99 | 3 | 2 | 4 | 2 | 11 | 1) Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.<br>2) Ф.Ф.Харисов, Г.Д.Сиражиева.Татар теле: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012. |

**!нче сыйныфның татар төркемнәре өчен татар теленнән календарь –тематик план.**

(атнага 3 сәгать исәбеннән, барлыгы 99 сәгать)

| № | Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | | Көтелгән нәтиҗәләр | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Махсус белем һәм күнекмәләр | | Универсаль уку күнекмәләре. | |
| | | | План | Фак. | Белем | Күнекмә | | |
| | | | | | **I. Телдән әзерлек чоры ( 32 сәг.)** | | | |
| **1** | **Танышу.** | **2** | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Укучы һәм укытучылар белән танышу. | 1 | | | Син кем? Исемең ничек? Ул кем? Аның исеме ничек? төзелмәләре. -мы/-ме? кисәкчәләре.әйе,юк, түгел сүзләре. Зат алмашлыклары. | Җөмләләрнең мәгънәләрен аңлап,Син кем? Синең исемең ничек? кебек сорауларга җавап бирү. Раслый белү һәм кире кагу.Зат алмашлыкларын кулланып , предметның кемгә караганлыгын белү. | Парта артында дөрес утыру, кул күтәрергә өйрәтү. Сорауга тулы җавап бирү. | |
| 2 | “Танышу” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләрнең дөрес әйтелеше | Сорауларны аңлап,дөрес җавап бирә белү. | Парлап эшли белү. | БСҮ |
| **2** | **Безнең мәктәп.** | **5** | | | | | | |
| 3 | Уку-язу әсбаплары.Сыйныф бүлмәсе. | 1 | | | Уку-язу әсбаплары.Нәрсә? соравы. | Нәрсә? соравына җавап бирү. Сыйныф бүлмәсендәге уку-язу әсбапларының исемнәрен дөрес әйтү. | Танып-белү активлыгын үстерү. | |
| 4 | Кемнең? соравына җавап бирү.әйбернең билгесен белдерү. | 1 | | | Зат алмашлыкларын кулланып,предметныңкемгә караганлыгын белдерү.Нинди? Кайсы? сораулары.Предмет-ның билгесен белдерүче сүзләр. | Зат алмашлыкларын сөйләмдә дөрес куллану.Предметның билгесен, барлыгы яки юклыгы турында хәбәр итү. | Эшчәнлек өчен эш урыны әзерләү. | |
| 5 | Ничә? соравы.Предметларның саны. | 1 | | | 1 дән 10 га кадәрге микъдар саннары.Ничә? соравы. | Ничә? соравына дөрес җавап бирү. Микъдар саннарын актив кулланышка кертү. | Рәсемнәр белән эшли белү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Сөйләмдә сан һәм исем тезмәләрен дөрес куллану. | | |
| 6 | Кая?Кайда? Нишли? сораулары. Предметның урыны һәм эше. | 1 | | | Кая? Кайда? сораулары.әйбернең (кешенең ) урыны турында хәбәр итү. Нишли? Ничек? сораулары. | Сорауларга дөрес җавап бирү. Кешенең,әйбернең үтәлү урыны турында хәбәр итү. Нишли? соравына дөрес җавап бирү, эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен ,формасын белдерү. | Белемнәрне практикада куллану. | |
| 7 | “Безнең мәктәп(сыйныф)” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләрнең дөрес әйтелеше | Раслау яки кире кага белү.Җөмләләр төзи белү. | Сөйләм телен үстерү. | БСҮ |
| **3** | **Безнең гаилә.** | **4** | | | | | | |
| 8 | Гаилә әгъзалары. Гаилә әгъзаларының эш-хәрәкәте. | 1 | | | Гаилә әгъзаларының аталышы. Хәрәкәтне белдерүче сүзләр. | Гаилә кешеләре,аларның исемен хәбәр итү. Гаилә әгъзаларының эш-хәрәкәте ,эш-хәрәкәтнең үтәүчесе,үтәлү вакыты һәм урыны турында хәбәр итү. | Сорауга тулы җавап бирү. | |
| 9 | Гаилә кешеләренең һөнәре, белгечлеге. | 1 | | | Һөнәр атамалары. | Гаилә кешеләренең һөнәре,белгечлеге турында хәбәр итү,сөйләмдә куллану. | Парлап эшли белү. | |
| 10 | өйдәге әйбер атамалары. | 1 | | | Җиһаз атамалары. | Җиһаз атамаларын сөйләмдә куллану.Аларның | Танып-белү активлыгын үстерү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | билгеләре,саны,уры-ны.турында хәбәр итү. | | |
| 11 | “Безнең гаилә” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләрнең дөрес әйтелеше | Сорауларны аңлап,дөрес җавап бирә белү. | Рәсемнәр белән эшли белү. | БСҮ |
| **4** | **Ашамлыклар.** | **2** | | | | | | |
| 12 | Савыт-саба. | 1 | | | Савыт-сабаның аталышы. | Бу темага караган атамаларны дөрес әйтү. | Җөмләләр төзи белү. | |
| 13 | Милли ризыклар. “Ашамлыклар” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Ашамлыкларның аталышы.Милли ризыклар. Кунакчыллык, табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. | Милли ризыкларны санап күрсәтү,аларны кертеп,гади җөмлә белән сорауларга җавап бирү.Ризыкны әзерләүче турында хәбәр итү.*Белән* бәйлеге+*фигыль* тезмәсен дөрес куллану. | Сораугa төгәл җавап бирә белү. | БСҮ |
| **5** | **Кеше.** | **3** | | | | | | |
| 14 | Тән әгъзалары. | 1 | | | Тән өлешләренең аталышы.Кайсы? соравы. | Тән төзелешенә караган атамаларны дөрес әйтә белү.Кайсы? соравына җавап бирергә өйрәнү. | Мөстәкыйль эшли белү. | |
| 15 | Шәхси гигиена әйберләре. Шәхси гигиенага караган эш-хәрәкәт. | 1 | | | Темага караган лексика. Эш-хәрәкәтне белдерүче сүзләр. | Сүзләрне дөрес әйтү һәм сөйләмдә куллану. Предметның санын хәбәр итү. Темага караган эш-хәрәкәт турында хәбәр итү.Эш-хәрәкәтнең үтәүчесе,аның объекты,үтәлү вакы-ты | Нәтиҗә ясау күнекмәләре булдыру. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | турында хәбәр итү. | | |
| 16 | “Кеше” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Тән әгъзалары.Шәхси гигиена кирәк-яраклары. | Сорауларны аңлап,дөрес җавап бирә белү. | Сөйләм телен үстерү. | БСҮ |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **6** | **Өс-баш һәмаяккиемнәре.** | **3** | | | | | | |
| 17 | Өс-баш  һәм аяк киемнәре.<br>Предметның билгеләре турында хәбәр итү. | 1 | | | өс-баш һәм аяк киемнәренең аталышы. Кемнеке? соравы. Предметның билгесен белдерүче сүзләр .Нинди? соравы. | Темага караган сүзләрне әйтә белү.Предметның кемнеке икәнлеге турында хәбәр итү.Аның барлыгын яки юклыгын белдерү.Аларның санын ачыклау. Предмет, аның билгеләрен дөрес билгели һәм әйтә белү. | Рәсемнәр белән эшли белү. | |
| 18 | Темага караган предметларның эш-хәрәкәте. | 1 | | | Эш-хәрәкәтне белдерүче сүзләр. Нишли?соравы. | Темага караган предметларның эш-хәрәкәте, эш-хәрәкәтнең объекты турында хәбәр итү. | Чагыштыра белү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 19 | “өс-баш  һәм аяк киемнәре” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләрнең дөрес әйтелеше. | Сорауларны аңлап,дөрес җавап бирә белү. | Сөйләм телен үстерү. | БСҮ |
| **7** | **Уеннар.** | **2** | | | | | | |
| 20 | Уеннар һәм уенчыклар. Уенда булган эш-хәрәкәтләр. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләр. Эш-хәрәкәтләрне белдерүче сүзләр.Нишли? соравы. | Темага караган сүзләрне сөйләмдә дөрес куллану.Предметлар-ның саны, билгесе, кемнеке икәнлеге турында хәбәр итү. Предметның урынын, аңа бәйле эш-хәрәкәтне белдерү. | Җөмләләр төзи белү. | |
| 21 | “Уеннар” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Уеннар һәм уенчык атамалары. | Балачакның яраткан уеннары турында әңгәмә. | Рәсем буенча хикәя төзү. | БСҮ |
| **8** | **Авылда.** | **3** | | | | | | |
| 22 | Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр. | 1 | | | Яшелчә һәм җиләк-җимеш исемнәре. | Темага караган сүзләрне сөйләмдә куллану.Аларның билгесен атау. | Рәсем буенча эшли белү. | |
| 23 | Кыргый хайваннар. | 1 | | | Кыргый хайваннарның аталышы.Кайда? соравы. | Кыргый һәм йорт хайваннарының исемнәрен әйтә белү.Аларның яшәү урыны турында хәбәр итү. | Грамматик категорияләрне сөйләмдә дөрес куллана белү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | Йорт хайваннары һәм кошлары.<br>“Авылда” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Йорт хайваннары һәм кошларының аталышы. | Темага караган предметларның саны турында хәбәр итү. Аларның эш-хәрәкәтен белдерү. | Сорауларга тулы җавап бирә белү. | БСҮ |
| **9** | **Кошлар.** | **2** | | | | | | |
| 25 | Күчмә һәм кышлаучы кошлар. | 1 | | | Кышлаучы һәм күчмә кошларның аталышы. | Кошлар исемен әйтә белү.Аларның яшәү урыны турында хәбәр итү. | Танып белү активлыгын үстерү. | |
| 26 | “Кошлар” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Кошларның исемнәре. | Безнең як кошлары турында сөйләшү. | Классификацияли белү. | БСҮ |
| **10** | **Шәһәрдә.** | **3** | | | | | | |
| 27 | Шәһәр, шәһәрдәге эш-хәрәкәтне белдерүче сүзләр. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләр. Предметларның билгесен,санын белдерүче сүзләр. | Предметларның исемнәре һәм билгеләре турында хәбәр итә белү. Предметның эш-хәрәкәтен, эш-хәрәкәтнең билгесен,үтәлү урынын һәм вакытын белдерү. | Сорауларга тулы җавап бирү. | |
| 28 | Эш-хәрәкәтнең билгесе, үтәлү вакыты,урыны. | 1 | | | Кайда? Кайчан? сораулары. | Темага караган предметларның эш-хәрәкәте, эш-хәрәкәтнең объекты турында хәбәр итү. | Танып белү активлыгын үстерү. | |
| 29 | “Шәһәрдә” темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Шәһәр тормышына караган атамалар. | Сорауларны аңлап,дөрес җавап бирә белү. | Сөйләм телен үстерү. | БСҮ |
| | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **11** | **Бәйрәмнәр.** | **3** | | | | | | |
| 30 | Бәйрәмнәр.Бәйрәмнәр белән котлау сүзләре. | 1 | | | Темага караган лексик берәмлекләр.Котлау сүзләре. | Котлау сүзләрен дөрес һәм урынлы куллану. | Сүзлек белән эшли белү. | |
| 31 | Милли бәйрәм – Сабантуй. | 1 | | | Сабантуй – милли бәйрәм. | Бәйрәмдә булган эш-хәрәкәтне белдерү. | Җөмләләр төзи белү. | |
| 32 | "Бәйрәмнәр" темасына бәйләнешле сөйләм үстерү. | 1 | | | Бәйрәмнәрнең аталышы.Аларны уздыру вакыты. | Бәйрәмнәрне санап күрсәтү.Аларны уздыру вакытын белү. | Сөйләм телен үстерү. | БСҮ |

## II. Әлифба чоры (47 сәг.)

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 33 | Сөйләм. | 1 | | | Әйтмә һәм язма сөйләм. | Хикәя төзи белә. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. | |
| 34 | Җөмлә. | 1 | | | Җөмлә, җөмлә схемасы. | Җөмләнең башын һәм ахырын таба белү. | Дәреслек белән эшли белү. | |
| 35 | Сүз. Җөмлә сүзләрдән тора. | 1 | | | Җөмләнең бер яки берничә сүздән төзелүен аңлау. | Рәсем эчтәлегенә һәм схемадагы сызыкларга карап, җөмләдәге сүзләрне әйтә белү. | Схема белән эшли белү. | |
| 36 | Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. | 1 | | | Сүзне иҗекләп әйтергә өйрәтү. | Схемада иҗек санын күрсәтә белү. | Ишетеп аңлый белү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37 | Аваз. Сузык һәм тартык авазлар. | 1 | | | Аваз төшенчәсен кертү. Сузык һәм тартык авазлар. | Авазларны ишетеп дөрес аера белү. | Классификация ләү. | |
| 38 | Сузык [а] авазы. А, а хәрефләре. | **1** | | | Авазларның хәрефләр белән белдерелүен аңлату. | Авазны дөрес әйтү, хәрефләрен яза белү. | Схема белән эшли белү. | |
| 39 | Сузык [ә] авазы. Ә, ә | 1 | | | Сузык [ә] авазы һәм | [ә] авазын ишетеп тану | Ручканы дөрес | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрефләре. | | | | аның хәрефләре. | һәм авазны дөрес әйтү. | тота белү. | |
| 40 | Сузык [ы] авазы. Ы, ы хәрефләре. | 1 | | | Сузык [ы] авазы һәм аның хәрефләре. Татар телендәге үзенчәлекләре. Калын һәм нечкә сузыклар. | Авазны дөрес әйтү. Хәрефләрне дөрес яза белү. | Уку, язу таләпләрен аңлау. | |
| 41 | Сузык [э] авазы. Э, э –е хәрефләре. | 1 | | | [э] авазының дөрес әйтелеше. Рус телендә киң әйтелүе. | Калын һәм нечкә сузыкларны аера белү. | Язганда дөрес утыру. | |
| 42 | Сузык [и] авазы. И, и хәрефләре. | 1 | | | [и] авазын дөрес әйтергә, и хәрефен таный белергә өйрәтү. Иҗек –аваз анализы. | Ике хәрефне кушып уку алуларына ирешү. | Белемнәрне практикада куллану. | |
| 43 | Сузык [у] авазы. У, у хәрефләре. | 1 | | | Сузык [у] авазы һәм аның хәрефләре. | Сөйләмнән сузык авазларны аера белеп, аларның хәрефләрен дөрес куя белү. | Кисмә хәрефләр белән эшли белү. | |
| 44 | Сузык [ү] авазы. Ү, ү хәрефләре. | 1 | | | Сузык [ү] авазы һәм аның хәрефләре. | Дөрес әйтү һәм язуда дөрес куллану. | Рәсемнәр белән эшли белү. | |
| 45 | Сузык [о] авазы. О,о хәрефләре. | 1 | | | Сузык [о] авазының әйтелеш үзенчәлекләре,о хәрефенең сүз башында яки беренче иҗектә генә язылуы. | Тар һәм киң әйтелешле авазларны дөрес әйтү. | Язганда дөрес утыру. | |
| 46 | Сузык [ө] авазы. Ө,ө хәрефләре. Сүзлек диктанты. | 1 | | | Сузык [ө] авазының әйтелеш үзенчәлекләре,ө хәрефенең сүз башында яки беренче иҗектә генә язылуы. | Сузык [ө] авазы кергән сүләрне дөрес әйтү. | Классификация ләү. | Сүз-лек дик-тант ы № 1 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 47 | Тартык [н] авазы. Н, н хәрефләре. | 1 | | | Тартык [н] авазы һәм аның хәрефләре. | Хәрефләрне яза белү. | Язганда дөрес утыру. | |
| 48 | Тартык [л] авазы. Л, л хәрефләре. | 1 | | | Тартык [л] авазы һәм аның хәрефләре. | Сузык һәм тартык авазларны аера белү. Сүзләрне дөрес уку. | Дәреслек белән эшли белү. | |
| 49 | Тартык [м] авазы. М, м хәрефләре. | 1 | | | Язылышы бертөрле,ләкин лексик мәгънәләре төрле булган сүзләр. | Сүзләргә фонетик анализ ясый белү. | Анализлый белү. | |
| 50 | Тартык [р] авазы. Р, р хәрефләре. | 1 | | | Авазның дөрес әйтелеше һәм язылышы. | Сүзләрне дөрес уку. | Сәнгатьлеуку. | |
| 51 | Тартык [й] авазы. Й, й хәрефләре.Сүзлек диктанты. | 1 | | | [йө], [йо] кушылмаларының сүз башында гына язылышы | [йө], [йо] кушылмалары кергән сүзләрне дөрес уку,язу. | Дөрес һә матур яза белү. | Сүз-лек дик-тант ы № 2 |
| 52 | Тартык [ң] авазы. ң хәрефе. | 1 | | | ң хәрефенә башланган сүзләрнең булмавы. | [ң] авазы кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне дөрес уку, язу. | Уку, язу таләпләрен аңлау. | |
| 53 | Я, я хәрефләре. | 1 | | | Я хәрефенең ике аваз белдерүе. | Я хәрефе кергән сүзләрне дөрес уку һәм дөрес язу. | Текст белән эшли белү. | |
| 54 | Ю, ю хәрефләре. | 1 | | | Ю хәрефенең ике аваз белдерүе. | Ю хәрефе кергән сүзләрне дөрес уку һәм дөрес язу. | Сөйләм телен үстерү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 55 | Сузык Е, е хәрефләренең [йы], [йэ] авазларын белдерүе. Сүзлек диктанты. | 1 | | | Е хәрефенең 2 аваз белдерүе. | Сүзләрне дөрес уку. | Классифика-цияләү. | Сүз-лек дик-тант ы № 3 |
| 56 | Тартык [д] авазы. Д, д хәрефләре. | 1 | | | [д] авазының әйтелеше. | Авазны дөрес әйтү, хәрефләрне дөрес язу. | Группаларда эшли белү. | |
| 57 | Тартык [т] авазы. Т, т хәрефләре. | 1 | | | Тартык [т] авазы һәм аның хәрефләре. Саңгырау тартыклар. | Авазны дөрес әйтү. Хәрефләрне тану һәм дөрес язу. | Таблицабелән эшли белү. | |
| 58 | Тартык [з] авазы. З, з хәрефләре. | 1 | | | Тартык авазларны яңгырау һәм саңгырау тартыкларга аеру. | Басма хәрефләр белән бирелгән текстны күчереп яза белү. | Дөрес һәм чиста язуны камилләштерү. | |
| 59 | Тартык [с] авазы. С, с хәрефләре. | 1 | | | [с] авазының әйтелеше. | Авазны дөрес әйтү, хәрефләрне дөрес язу. Сүзләр һәм җөмләләр төзү, уку. | Дәреслек белән эшли белү. | |
| 60 | Тартык [гъ], [г] авазы. Г, г хәрефләре. | 1 | | | Кече тел тартыгы [гъ] авазының әйтелеше . [г] авазының әйтелешеннән аермасы. | [гъ], [г] авазларын дөрес әйтү, сүзләрне дөрес уку. | Чагыштыра белү. | |
| 61 | Тартык [къ], [к] авазы. К, к хәрефләре. | 1 | | | Тартык [къ], [к] авазларының дөрес әйтелеше. | Авазларны бер-берсеннән әйтелеш буенча аеру. | Кроссворд-лар белән эшли белү. | |
| 62 | В, в хәрефләре. Ирен-ирен [w] һәм ирен-теш [в] авазлары. Сүзлек диктанты. | 1 | | | Ирен- ирен [w] авазының әйтелеш үзенчәлекләре. [в] авазы һәм аның | В хәрефе кергән сүзләрне дөрес уку һәм дөрес язу. | Чагыштыра белү. | Сүз-лек дик- |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хәрефләре | | | тант ы № 4 |
| 63 | Тартык [ф] авазы. Ф, ф хәрефләре. | 1 | | | [ф] авазының әйтелеше һәм язылышы. | Сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Дөрес һәм чиста язуны камилләштерү | |
| 64 | Тартык [б] авазы. Б, б хәрефләре. | 1 | | | [б] авазының әйтелеше һәм язылышы. | Б хәрефе кергән сүзләрне дөрес уку һәм дөрес язу. | Текст белән эшли белү. | |
| 65 | Тартык [п] авазы. П, п хәрефләре | 1 | | | Яңгырау һәм саңгырау тартыкларның әйтелеш үзенчәлекләре | Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны ишетеп тану | Классификация ләү һәм гомуми нәтиҗә чыгару. | |
| 66 | Тартык [ж] авазы, Ж, ж хәрефләре. | 1 | | | [ж] авазының кулланылыш үзенчәлеге. | Шул аваз кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Парлап эшли белү. | |
| 67 | Тартык [ш] авазы, Ш, ш хәрефләре. | 1 | | | [ш] авазының әйтелеше һәм язылышы. | Ш хәрефе кергән сүзләрне дөрес уку һәм дөрес язу. | Текст белән эшли белү | |
| 68 | Тартык [җ] авазы. Җ, җ хәрефләре. | 1 | | | Татар теленә генә хас булган тартык [җ] авазы. Аның әйтелеше. | Шул аваз кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Классификация ләү. | |
| 69 | Тартык [ч] авазы. Ч, ч хәрефләре. | 1 | | | [ч] авазының кулланылыш үзенчәлеге. | [ч] авазын язуда дөрес күрсәтү,авазны ишетеп тану. | Чагыштыра белү. | |
| 70 | Тартык [х] авазы. Х, х хәрефләре. | 1 | | | [х] авазының әйтелеш үзенчәлеге. | Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аера белү. | Рәсем белән эшли белү. | |
| 71 | Тартык [һ] авазы. Һ, һ хәрефләре | 1 | | | Татар теленә генә хас булган тартык [һ] авазы. Аның әйтелеше. | [х] һәм [һ] авазларын аера белү. | Дәреслек белән эшли белү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 72 | Күчереп язу “Иртән” | 1 | | | Татар алфавитындагы хәрефләрнең дөрес язылышы. | Текстны аңлап,дөрес итеп күчереп яза белү. | Дөрес һәм чиста язуны камилләштерү. | Күче -реп язу №1 |
| 73 | Хаталар өстендә эш. Тартык [ё] авазы. Ё, ё хәрефләре | 1 | | | [ё] авазының рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланылуы. | Шул аваз кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Чагыштыра белү. | |
| 74 | Тартык [щ] авазы. Щ, щ хәрефләре. | 1 | | | [щ] авазының рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланылуы. | Сүзләрне дөрес әйтү һәм дөрес язу. | Белемнәрне практикада куллану. | |
| 75 | Тартык [ц] авазы. Ц, ц хәрефләре. | 1 | | | Ц хәрефенең рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланылуы. | Янәшә тартык булган сүзләрне дөрес уку һәм дөрес язу. | Рәсем белән эшли белү. | |
| 76 | Ь (нечкәлек һәм аеру) билгесе. | 1 | | | Нечкәлек һәм аеру билгесенең функцияләре белән танышу. | Ь билгесе булган сүзләрне дөрес язу һәм уку. | Кагыйдәләрне аңлап кабул итү. | |
| 77 | Ъ (калынлык һәм аеру билгесе) | 1 | | | Калынлык һәм аеру билгесенең функцияләре белән танышу. | Ъ билгесе булган сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Чагыштыра белү. | |
| 78 | Диктант “Кошлар килә” | 1 | | | Татар алфавитындагы хәрефләрнең дөрес язылышы. | Текстны аңлап,дөрес итеп күчереп яза белү. | Дөрес һәм чиста язуны камилләштерү. | Дикт ант №1 |
| 79 | Хаталар өстендә эш. Татар алфавитын кабатлау. | 1 | | | Хәрефләр турында алган белемнәрен гомумиләштерү. | Татар алфавитын белү. | Хәтерен үстерү. | |
| **III Грамматика (20 сәгать)** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 80 | Сөйләм. Аралашу әдәбе. | 1 | | | Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. | Язма һәм телдән сөйләм төзү,аларны аера белү. | Сөйләм телен үстерү. | |
| 81 | Сүз. Сүз һәм иҗек. | 1 | | | Иҗек. Сүзләрнең иҗекләргә бүленеше. | Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес итеп әйтү һәм язу. | Белемнәрне практикада куллану. | |
| 82 | Авазлар һәм хәрефләр. | 1 | | | Аваз һәм хәреф аермасы. Алфавитны белү. | Хәрефнең исемен, аның авазын дөрес атау. | Дәреслек белән эшли белү. | |
| 83 | Алфавит. Алфавитныкүчерепязу. | 1 | | | Алфавитта хәрефләр нең билгеле бер тәтиптә урнашуы. Хәрефләрне тоташ итеп дөрес һәм матур язарга өйрәтү. | Алфавитны куллана белү. Дөресһәмматурязу. | Истә калдыру. Күчерепязу. | |
| 84 | Баш хәрефтән языла торган сүзләр. Күчереп язу “Татарстан” | 1 | | | Баш хәрефтән язылучы сүзләр. | Кеше исемнәрен, хайван кушаматларын, елга, авыл, шәһәр исемнәрен дөрес язу. | Матур һәм дөрес яза белү. | Күче реп язу №2 |
| 85 | Хаталар өстендә эш.Сузык авазлар. | 1 | | | Калын һәм нечкә сузыклар. | Сузыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. | Классификация ли белү | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 86 | Тартык авазлар. | 1 | | | Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. | Тартыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. | Чагыштыру һәм нәтиҗә чыгару. | |
| 87 | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. | 1 | | | Юлдан-юлга күчерү кыгыйдәләре. | Сүзләрне иҗекләргә бүлү. | Кагыйдәләрне аңлап, гамәлдә куллану. | |
| 88 | Сузык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу. | 1 | | | Э-э, ө-е, о-ы хәрефләренең дөрес язылышы. | Э-э(е),ө-е, о-ы хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу. | Сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру. | |
| 89 | Я,ю,е хәрефләре | 1 | | | Хәрефләрнең дөрес язылу кагыйдәләре. | Я ,ю,е хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Дөрес һәм чиста язуны камилләштерү. | |
| 90 | Тартык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу. | 1 | | | Й, в,к,г хәрефләренең дөрес язылышы. | Й, в,к,г хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. | Кагыйдәләрне аңлап, дөрес кабул итү күнекмәсен үстерү. | |
| 91 | Диктант “Май ае” | 1 | | | Үтелгән лексик-грамматик материал. | Ишетеп дөрес яза белү. | Алган белемнәрне системалаштыру. | Диктант № 2 |
| 92 | Хаталар өстендә эш. Й, в,к,г хәрефләренең дөрес язылышы. | 1 | | | Аваз һәм хәреф аермасы. Алфавитны белү. | Хәрефнең исемен, аның авазын дөрес атау. | Дәреслек белән эшли белү. | |
| 93 | Сүз басымы. | 1 | | | Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Басымны дөрес кую. | Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Басымны дөрес кую. | Кагыйдәләрне аңлап, дөрес кабул итү күнекмәсен үстерү. | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 94 | Исем сүз төркеме. | 1 | | | Сүз төркеме турында төшенчә. Исемнең мәгънәсе, сораулары. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәренең дөрес язылышы. | Алган белемнәрне системалаштыр у. | |
| 95 | Фигыль сүз төркеме. | 1 | | | Фигыльнең барлык-юклык формалары турында төшенчә бирү. Сораулары. | Нишли?нишлиләр? нишләми? нишләмиләр? сорауларына җавап бирә белү. | Кагыйдәләрне аңлап, гамәлдә куллану. | |
| 96 | Сыйфат сүз төркеме. | 1 | | | Сыйфат, аның мәгънәсе, сораулары. | Нинди? кайсы? сорауларына җавап бирә белү. | Дөрес һәм чиста язуны камилләштерү | |
| 97 | Җөмлә. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | 1 | | | Җөмлә, вазифасы, функциясе турында белемнәрне үзләштерү. Җөмләдә сүзләр арасындагы бәйләнеш. | Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзү. | Сөйләм телен үстерү. | |
| 98 | Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. | 1 | | | Хикәя, өндәү, сорау җөмләләр. | Тыныш билгеләренә карап, җөмләләрне дөрес интонация белән әйтә белү. | Белемнәрне практикада куллану. | |
| 99 | Өйрәнгәннәрне йомгаклау. | 1 | | | Белемнәрне гомумиләштерү, системага салу. | Белемнәрне искә төшерү һәм практикада куллана белү. | Гомуми нәтиҗә чыгара. | |

**Татар теленнән өйрәтү характерындагы язма эшләр төре.**

| Эш төре | Тема | Үткәрү вакыты. | |
|---|---|---|---|
| | | Программа буенча | Фактик |
| Күчереп язу №1 | Иртән | | |
| Күчереп язу №2 | Татарстан | | |
| Диктант № 1 | Кошлар килә | | |
| Диктант № 2 | Май ае | | |
| Сүзлек диктанты №1 | Сузык [ө]авазы.Ө,ө хәрефләре. | | |
| Сүзлек диктанты № 2 | Тартык[й]авазы. Й,й хәрефләре. | | |
| Сүзлек диктанты № 3 | Сузык Е,е хәрефләренең [йы],[йэ] авазларын белдерүе. | | |
| Сүзлек диктанты № 4 | В,в хәрефләре.Ирен-ирен[w] һәм ирен-теш [в] авазлары. | | |

**Сөйләм үстерү өчен темалар.**

Танышу.
Безнең мәктәп(сыйныф).
Бәйрәмнәр.
Безнең гаилә.
Ашамлыклар.
Кеше.
Өс-баш киемнәре.
Аяк киемнәре.
Уенда.
Авылда.
Кошлар.
Шәһәрдә.

**Укучыларның татар теленнән белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары**

**I. Телдән җавап бирүне бәяләү**

Укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшергәндә һәм бәяләгәндә, билге җавапның сыйфатына карап һәм түбәндәге таләпләрне искә алып куелырга тиеш:

1) сөйләмнең орфоэпик, интонацион һәм грамматик яктан дөреслеге һәм төгәллеге;
2) сөйләмнең эчтәлеге ягыннан дөреслеге, тулылыгы һәм эзлеклелеге;
3) сөйләмнең аңлаешлылыгы;
4) сөйләмдә сүз байлыгы, җөмлә калыпларының төрлелеге.

Җавапның бәяләгендә, укытучы анның уңай һәм кимчелекле якларын әйтеп, хаталар яңадан кабатланмасын өчен, киләчәктә нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеген күрсәтергә

**1.Тыңлап аңлау күнекмәләрен бәяләү**

Тыңлап аңлау күнекмәләрен бәяләү өч төрле була:

1) “тулаем аңлады”;
2) “өлешчә аңлады”;
3) “аңламады”.

**2.Укучының монологик сөйләмен бәяләү:**

Бирелгән тема (рәсем яки ситуация) буенча хикәя төзи белсә; дөрес интонация белән,тулы,эзлекле итеп,текст эчтәлегенә үз мөнәсәбәтен,бәясен биреп сөйли алса, тупас булмаган пауза хаталары булса да, “5” ле куела.

1 нче сыйныфта бәйләнешле сөйләм 5-6, 2 нче сыйныфта 7-8, 3 нче сыйныфта 8-9, 4 нче сыйныфта 10-12 җөмлә тәшкил итә.

Аерым паузалар, 1-2 сөйләм хатасы ясаса, укытучы тарафыннан 1-2 ачыклаучы сорау бирелсә, “4”ле куела.

Теманың төп эчтәлеген ачса, 4-6 сөйләм хатасы җибәрсә, укытучы тарафыннан икедән артык ачыклаучы сорау бирелсә яки укытучы ярдәменнән башка сөйләмне башлый (тәмамлый) алмаса, “3”ле куела.

Сөйләмдә эзлеклелек сакланмаса, паузаларда төгәлсезлекләр китсә, 6 дан артык сөйләм хатасы һәм грамматик хата ясаса, “2” ле куела.

**3.Диалогик сөйләмне бәяләү**

Тиешле темпта дөрес интонация белән сорау куйса,әңгәмәдәшенең сорауларына тулы җавап кайтарса, “5” ле куела.

Дөрес сорау биреп, үзе дә әңгәмәдәшенең соравына дөрес җавап кайтарса, ләкин сөйләм вакытында укытучы ярдәменә мохтаҗ булса, 2-3сөйләм хатасы җибәрсә, “4” ле куела.

Укытучы ярдәмендә генә сорау бирсә яки җавап кайтарса, сораулар биргәндә,сүзләр һәм грамматик формалар табуда төгәлсезлекләр җибәрсә яки өйрәнгән җөмлә калыпларының бер өлешен генә үзләштерсә, 4-5 сөйләм хатасы җибәрсә, “3” ле куела.

Әңгәмә вакытында зур авырлык белән генә сорау бирсә, сорауларга үз көче белән җавап бирә алмаса, 6 дан артык хата җибәрсә, “2” ле куела.

## II. Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү

Телдән сөйләү белән бергә, башлангыч сыйныфларда язу күнекмәләре дә формалаштырыла. Моның өчен түбәндәге язма эшләр башкарыла:

1) татарча сүзләрне, сүзтезмәләрне,җөмләләрне, текстларны күчереп яки ишетеп язу;
2) сорауларга җавап язу;
3) сүзлек яки конроль диктантлар язу;
4) изложениеязу;
5) сочинение язу.

Матур язуга караган кимчелекләрне төзәтү дә язу күнегүләренә керә. 1 нче сыйныфта һәр укучының, 2-4 нче сыйныфта кайберләренең дәфтәрләренә аерым хәрефләрне язу үрнәкләре бирелә.

Матур язуның күләме: 1 нче сыйныфта 1 юл, 2 нче сыйныфта 2 юл, 3-4 нче сыйныфларда 3 юлдан артмаска тиеш. Бу эш һәр дәрестә алып барыла: язма эшләр тикшерелә, укучылар белән бергә хаталарны төзәтү өстендә эш үткәрелә.

**Тикшерү характерындагы язма эшләр күләме.**

| Сыйныфлар | Эш төрләре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Сүзлек диктанты. | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
| 1 | - | - | - | - |
| 2 | 4 | 4 | 1 | 1 |
| 3 | 4 | 4 | 1 | 1 |
| 4 | 4 | 5 | 1 | 1 |

Күчереп язу өчен, аерым сүзләр, җөмләләр, зур булмаган бәйләнешле текстлар алына.

**Күчереп язу өчен сүз һәм җөмләләр күләме.**

| Сыйныфлар | Эш төрләре | |
|---|---|---|
| | Сүзләр | Җөмләләр |
| 1 | 6-8 | 2-3 |
| 2 | 8-13 | 4-5 |
| 3 | 13-20 | 6-8 |
| 4 | 20-35 | 9-11 |

**Күчереп язуны бәяләү**

Пөхтә итеп язылган, орфографик хаталары булмаган, ләкин 1-2 җирдә хәрефләрнең урыны алышынган булса, “5” ле куела.
Эш бик үк чиста итеп башкарылмаса, 1-2 хата җибәрелсә, хәрефләрнең урыны алышынса, “4” ле куела.

Язуда 3-5 хата җибәрелсә яки хәрефләрнең урыны алышынса, текст пөхтә итеп язылмаса, төзәтүләр күп булса, “3” ле куела.
Хаталар саны 5 тән артса, төзәтүләр күп булса, “2”ле куела.

## 2-4 нче сыйныфларда диктантларны бәяләү

Диктант (1 нче сыйныфта уку елының 2 нче яртысыннан уздырыла башлый), изложение, сочинениеләрдәге сүзләр саны түбәндәгечә була.

| Сыйныфлар | Эш төрләре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Сүзлек диктанты. | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
| 1 | 5-7 | 10-15 | - | - |
| 2 | 7-10 | 20-25 | 15-20 | 10-15 |
| 3 | 10-12 | 25-30 | 20-25 | 15-20 |
| 4 | 12-16 | 30-35 | 25-35 | 20-25 |

Диктант итеп аерым сүзләр яки текст яздырыла. Аны уздыру вакытын укытучы үзе билгели. Аерым сүзләрне дөрес язу күнекмәләрен тикшерү өчен сүзлек диктантлары үткәрелә.
1-2 нче сыйныфларда орфографик хаталар гына искә алына. 3 нче сыйныфта аларга тыныш билгеләренә караганнары да өстәлә.
Хатасыз яки тупас булмаган 1 хата җибәрелгән, дөрес каллиграфия белән матур итеп язылган эшкә “5” ле куела.
3 тән артык хата булмаган һәм пөхтә итеп язылган; хатасыз, ләкин төзәтүләр белән бик үк пөхтә язылмаган эшкә “4” ле куела.
5 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә “3”ле куела.

## Изложение һәм сочинениеләрне бәяләү

Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә, хаталар булмаса яки 1 орфографик ( 1 җөмлә төзелешендә ) хата җибәрелсә, “5” ле куела.
Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса яки пөхтә башкарылып, эзлеклелек булып та, сүз сайлауда һәм җөмлә төзүдә 2-3 хата булса, “4” ле куела.
Текстның яки рәсемнең төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса; 4-6 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда һәм җөмләләр төзегәндә, 4-5 төгәлсезлек китсә, “3” ле куела.
Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса; 7-10 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда, җөмләләр төзегәндә, 6-7 хата китсә, “2”ле куела.

**1 класс уку**

**Класс:** 1

**Укытучы:** Гарипова Гөлназ Мөнәвир кызы

**Атналык сәгатьләр саны:** 1, **барысы**: 33

**Программа:** “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Г.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)

**Дәреслек:** “Әлифба” (Р.Г.Вәлитова, С.Г.Вагыйзов. Казан, “Мәгариф”нәшрияты, 2009.), “Уку китабы” (Р.Х.Ягъфәрова. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2008).

**Өстәмә әдәбият:** “Әлифба белән ничек эшләргә” (Р.Г.Вәлитова, С.Г.Вагыйзов. Казан, “Татарстан китап нәшрияты”, 1986.), “Матур язу дәресләре” (С.Г.Вагыйзов. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 1999.)

**Стандарт:** “Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты”(Ф.Ф. Харисов, Ч.М.Харисова, В.Х.Хаков, Г.Г.Измайлова, Э.Х.Хәмидуллина.Казан, 2005**.)**

## Аңлатма язуы

***Эш программасы статусы.***

Программа нигезенә Россия, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары салынды, “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”на нигезләнеп төзелде.

***Эш программасы структурасы***.

Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.***

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”. Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.

1 нче сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән программа түбәндәге бурыч һәм максатларны куя:

- уку күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү;
- укуга, китапка кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү;
- матур әдәбият, аның авторы, әсәрнең жанры, персонажы турында күзаллау булдыру;

- дөрес һәм бәйләнешле әйтмә һәм язма сөйләмгә өйрәтү;
- әдәби әсәрләр йогынтысында үз-үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре булдыру.

### *Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы*

Татар халкының бай әдәби мирасын үзләштерү, халыкның гражданлык һәм мәдәни үткәнен белү яшь буынга аң-белем һәм тәрбия бирү, аларның милли үзаңын үстерү мөһим роль уйный. Әдәби уку программасына текстларның күбесе балалар әдәбиятыннан һәм әдәби әсәрләрдән сайланып, табигать, кешенең табигатькә мөнәсәбәте, аның табигатьне саклаудагы роле, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр кебек бүгенге заман проблемаларына туры килә. Шактый текст фольклордан алына. Эчтәлеге укучыларга якын булган әкиятләр, татар халкының мәзәкләре, мәкальләре һәм әйтемнәре, табышмаклар һәм тел шомарткычлар укучыларда зирәклек, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләүгә өлеш кертә.

1 нче сыйныфта укучылар аваз белән хәрефне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль кебек сүз төркемнәре турында башлангыч мәгълүмат алалар. Сөйләм берәмлеге буларак җөмлә, аларны төрле интонация белән әйтү, сүзләрдән – җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү күнекмәләре бирү дә әһәмиятле. Укучыларның татар телен белү дәрәҗәсен исәпкә алып, укытучы дәресләрдә татар һәм рус теле үзенчәлекләренә тукталырга, тәрҗемә өлкәсенә караган биремнәр дә тәкъдим итәргә тиеш.

### *1 нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр*

Уку елы ахырында 1 нче сыйныф укучылары, “Телдән әзерлек чоры” өчен тәкъдим ителгән темалар буеча бирелгән сүзләрне аңлап, кара-каршы һәм монологик сөйләмдә куллана белергә тиешләр. Укытучы, сыйныфтагы укучыларның белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, үрнәктә бирелгән сүзләрне үзгәртә, арттыра ала.

Хәрефләрдән – иҗекләр, иҗекләрдән – сүзләр, сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү. Сүз басымын дөрес куеп уку.

Татар теленең үзенчәлекле сузык һәм тартык авазларын дөрес әйтү, бу авазларны белдергән хәрефләр булган сүзләрне язу. Татар теленең үзенчәлекле авазлары кергән сүзләрдәге аваз һәм хәрефләрне аерып әйтә белү.

Җөмләләрдән исем, фигыль, сыйфатларны табу. Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен аңлату. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.

### *1 нче сыйныфта укудан үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр*

1 нче сыйныфта “Телдән әзерлек чоры”нда, татар әдәби тел нормаларына өйрәтү өчен, унбер тема һәм аларның тасвирламалары бирелде. Алар буенча әңгәмәләр оештыру – бик җаваплы эш, чөнки балаларның күбесе беренче тапкыр тематик принцип нигезендә системалы рәвештә татарча сөйләшү күнекмәләре булдыра башлый. Шуңа күрә эшнең ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булачагы әйтелгән этапның уңышлы үтүенә бәйле.

“Телдән әзерлек чоры” өчен сүзләр үрнәк буларак тәгъдим ителә. Кайсы дәрестә ничә һәм нинди сүз өйрәнүне укытучы үзе хәл итә, чөнки татар теле – рус җирлегендә яшәсә дә, татар баласы өчен ана теле, андагы күп сүзләр укучыга таныш булырга мөмкин.

“Әлифба чоры”нда татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү, алар белән иҗекләр, сүзләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзетү күз уңында тотыла. Әйтелешнең үзенчәлекләрен балаларга күрсәтүдә техник чаралардан файдалану, дәресләрдә төрле уеннар уйнау да уңай нәтиҗәләргә китерә.

Хәрефләрдән иҗекләр төзү, аннан соң иҗекләрдән – сүзләр, сүзләрдән сүзтөзмәләр төзеп уку. Сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү.

Эчтәлеген  аңлап, кирәкле урыннарда паузалар ясап, сүз басымын дөрес куеп уку.

Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар белән ([б], [п], [д],[т], [ж], [ш], [з], [с],  [и], [й], [л], [м], [н], [р], [у], [ф], [ц], [щ])танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.

[а],[о],[э/е],[w],[гъ],[къ],[х],[ч],[ы] авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.

Татар телендәге [ә], [ө], [ү], [җ], [ң], [һ] авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес уку.

“Әлифбадан соңгы чор”да “Уку һәм сөйләм үстерү”, “Ятлау өчен әсәрләр”, “Сөйләшү тематикасы” кебек бүлекләр бирелгән. Дәреслектә алар тематик принципта төзелгән.

Сөйләшү тематикасы үтелгән материалдан, аңа бәйле лексик-фразеологик минимумнан чыгып билгеләнде. Ул укучыларда әдәпле сөйләм формалаштыру максатын күздә тотып кертелде. Билгеле, укытучы аны сыйныф саен тирәнәйтә һәм баета барырга тиеш.

Укыту планында 1 нче сыйныфта укудан атнага 1 сәгать вакыт бирелә. Укудан тематик планны  “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын  укыту программасы”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Г.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)  нигезләнеп төзедем.

Программада 33 сәгать каралган: Телдән әзерлек чоры – 3 сәгать, Әлифба чоры – 23 сәгать, Әлифбадан соңгы чор. Уку – 7 сәгать.

| № | Төп темалар | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Телдән әзерлек чоры | 4 сәгать |
| 2 | Әлифба чоры | 21 сәгать |
| 3 | Әлифбадан соңгы чор. Уку | 8 сәгать |
| | Барлыгы | 33 сәгать |

***Укыту – методик комплекты***

1 “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова, В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Г.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)
2. Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. (Ф.Ф. Харисов, Ч.М.Харисова, В.Х.Хаков, Г.Г.Измайлова, Э.Х.Хәмидуллина. Казан, 2005.)
3. Әлифба. (Р.Г.Вәлитова, С.Г.Вагыйзов. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2009.)
4. Уку китабы. (Р.Х. Ягъфәрова. Казан, ”Мәгариф” нәшрияты, 2008.)

**Әдәби уку дәресләрен тематик планлаштыру**
(атнага 1 сәгать исәбеннән, барлыгы 33 сәгать)

| № п/п | Дәрес темасы | Сәг. саны | Дәрес тибы | Укучылар эшчәнлегенә характеристика | Материалны үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | План буенча | Факт. |
| 1. | Кереш дәрес. Сөйләм. | 1 | Яңа белем бирү. | Җәйге истәлекләр турында әңгәмә. Әлифба белән таныштыру. Сораулар буенча җөмләләр төзү. Шигырь ятлау. | Сөйләмнең кешеләргә аралашу өчен кирәклеген белергә. | | |
| 2. | Җөмлә төзелеше. Сүз. | 1 | | Җөмләләр төзү, схемада җөмлә башында һәм ахырда нокта куюга күнегүләр, җөмләне сүзләргә аеру. Һәр сузык бер сүз икәнлеген күрсәтү. | Җөмләнең сүзләрдән торуын белергә, схемадан һәр җөмләнең сүзләрен күрсәтә белергә. | | |
| 3. | Иҗек. | 1 | | “Эт, песи, карга” мәзәген сөйләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, практик күнегүләр. | Сүзнең һәр кисәге иҗек дип аталуын, һәр иҗектәге сузыкны көчлерәк тавыш белән әйтергә, сузарга кирәклеген белергә. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Аваз. Сузык һәм тартык авазлар. | 1 | Яңа белем бирү. | Авазларны әйтү һәм ишетү күнегүләре (бүре улаганда, эт ырылдаганда, бозау мөгрәгәндә, ишетмәгәндә, врач караганда чыккан авазлар); дәреслектәге схемаларны тикшерү;<br>Калын һәм нечкә сузыкларны парлап әйтү; тартыкларны дөрес әйтү күнеүләре. | Сүзнең авазларга бүленешен күрсәткән схеманы укый һәм үзе аңлатып сыза яки төзи белергә күнектерү.<br>Сузыкларны һәм тартыкларны аера белергә. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | [А]авазы, А, а хәрефләре.<br><br>[Ә] авазы, Ә ә хәрефләре. (15-16 б.) | 1 | Яңа белем бирү. | Сөйләмнән җөмлә, җөмләдән кирәкле сүзне аеру; сузыклар санына карап сүзне иҗеккә бүлү, калын яки нечкә иҗекне билгеләү; [а]авазын сүздә дөрес әйтергә, сүз эчендә ишетеп таныту; басмача хәрефләр белән танышу; дәреслектән уку; рәсем буенча җөмләләр төзү. Гаилә турында әңгәмә; һәркайсына карата җөмлә төзү; әби сүзенә иҗек-аваз анализы; Ә ә хәрефләре белән танышу; кисмә хәрефләрдән Ә ә не күрсәтү; “Ике кәҗә бәтие”нең эчтәлеге сөйләтелә. Кушылмалар табыла. | [А] авазын ишетә, А а хәрефләрен танырга; калын сузык булуын белергә; “баш А хәрефе”, юл а хәрефе” дип әйтә белергә.<br><br>[Ә] авазын әйтә,Әә хәрефләрен таный, нечкә сузык икәнлеген белергә. | | |
| 6. | [И] авазы, И и хәрефләре. (17 б.)<br><br>[Ы] авазы, Ы ы хәрефләре. | 1 | Яңа белем бирү. | Рәсем буенча сөйләтелә, схема буенча җөмлә төзиләр. сузык [и] авазы һәм Ии хәрефләре белән танышалар. сүзләргә иҗек-аваз анализы ясала. Ылыс сүзенә иҗек-аваз анализы; Сүзләрдән ы авазын табу; [и] белән [ы] чагыштыру; Калын, нечкә сузыкларны өйтү (а,у, ә,и); Дәреслек белән эшләү. | [И] авазының нечкә сузык булуын белергә. Ии хәрефләрен танырга. кеше исемнәре баш хәреф белән язылуын белергә, кушылмаларны таба белү күнекмәсе. [ы] авазы һәм Ыы хәрефләре;предметларны охшаш яклары буенча берләштерү; Рәсем буенча җөмләләр төзи белү. | | |
| 7. | [Ү] авазы, Ү, ү хәрефләре<br><br>[У] авазы, У, у хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Нечкә [Ү] авазын ишетеп тану, уен “Ү” дән башланган сүзләр”, “Сертотмас үрдәк” әкиятен сөйләү. 21-22 битләр. Калын һәм нечкә сузыкларны ишетеп тану, “Тартык аваз-сузык аваз” уены, рәсем эчтәлеген сөйләтү, иҗекләрне уку. 23-24 битләр. | [Ү] авазын дөрес әйтергә өйрәнү, җөмлә схемасын төзү, аны сүзләргә таркату, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү. У, у хәрефләрен һәм өйрәнгән барлык сузык хәрефләрне укый белергә. | | |
| 8. | [Л] авазы, Л, л хәрефләре<br><br>[Т] авазы, Т, т хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Яңгырау [Л] авазын аерып тану, иҗекләр, сүзләр, текст уку, кисмә хәрефләр белән эш. 25-26 битләр. Саңгырау [Т] авазын тану, ике хәрефле ачык һәм ябык иҗекләр уку, кисмә хәрефләр белән эш, сөйләм төзү. 27-28 битләр. | Сөйләмдә [Л] авазын әйтә белергә һәм ишетеп танырга өйрәтү. Сүздә [Т] авазын әйтергә, танырга, иҗекләп сүзләр, җөмләләрне укый белергә | | |
| 9. | [Н] авазы, Н, н хәрефләре<br><br>[С] авазы, С, с хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Яңгырау [Н] авазын аерып тану, иҗекләр, сүзләр, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү. 29-32 битләр. Саңгырау тартык [С] авазын аерып тану, иҗекләр, сүзләр, текст уку, “Су анасы” әкиятен сөйләү. 33-36 битләр | Н, н хәрефләре белән иҗекләр, сүзләр, текст укый белергә. С, с хәрефләре белән иҗекләр, сүзләр, текст укый белергә, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | [К, къ] авазлары, К, к хәрефләре<br><br>[Р] авазы, Р, р хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | [К, къ] авазларын ишетеп тану, алар белән кушылмалар төзү, уку, рәсем буенча эш. 37-40 битләр.<br>Р, р хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, карга турында шигырь ятлау, агач исемнәрен өйрәнү.41-44 бит. | [К, къ] авазларын дөрес әйтергә, укырга. Сүздә [Р] авазын әйтергә, ишетеп танырга, агач исемнәрен һәм текстны укый белергә. | | |
| 11. | [Е] авазы, Е, е хәрефләре<br><br>[Э-е] авазлары, Э, э хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | [йы], [йэ] авазы, Е, е хәрефләре белән танышу, сүзләр, җөмләләр, текст уку. 45-46 битләр.<br>Энә сүзен анализлау, таблицадагы сүзләрне, текстны уку, рәсемнең эчтәлеген сөйләү. 47-48 бит. | Е, е хәрефләренең 2 аваз белдерүен, аларны дөрес итеп әйтергә, укырга. Язганда [Э] авазының сүз башында – Э,э, кушылмаларда е хәрефе белән күрсәтелүен белергә, дөрес укырга. | | |
| 12. | [Г, гъ] авазлары, Г, г хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | [Г, гъ] авазларын дөрес әйтү, суган, гөл сүзләрен схема буенча анализлау, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү.<br>49-52 битләр. | Сүздә [Г, гъ] авазларын дөрес әйтергә, укырга. Г, г хәрефләренең калын сузык аваз хәрефләре янында [гъ] дип,нечкә сузык аваз хәрефләре янында [г] дип укылуын белергә. | | |
| 13 | [Д] авазы, Д, д хәрефләре<br>[Б] авазы, Б, б хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | [Д] авазы, Д, д хәрефләре белән танышу, Д авазыннан башланган сүзләр уйлау, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү. 53-56 битләр.<br>[Б] авазы, Б, б хәрефләре белән танышу, сүзләр, җөмләләр, текст уку.<br>57-60 битләр. | Д, д хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә.<br>Б, б хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. | | |
| 14 | [Ч] авазы, Ч, ч хәрефләре<br><br>[Ш] авазы, Ш, ш хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Саңгырау тартык [Ч] авазы, Ч, ч хәрефләре белән танышу, кушылмалар, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, ребус чишү. 61-64 битләр.<br>Тартык [Ш] авазын дөрес әйтергә, ишетеп танырга өйрәтү, такмак өйрәнү, кисмә хәрефләр белән эш, кышкы уеннар турында әңгәмә.<br>65-68 битләр. | Сүздә [Ч] авазын дөрес әйтергә, танырга, Ч, ч хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә.<br>Сүздә [Ш] авазын дөрес әйтергә, танырга, Ш, ш хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. | | |
| 15. | [М] авазы, М, м хәрефләре<br>[Й] авазы, Й, й хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Мәк сүзен анализлау, [М] авазына характеристика бирү, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш, иген, икмәк, ашлык сүзләренең мәгънәләрен ачыклау. 69-72 битләр.<br>Сузыктан соң килгән тартык [Й] авазы, ы, й хәрефләре белән белдерелгән калын ый сузыгы белән танышу, сүзләр, җөмләләр, текст уку.<br>73-74 битләр. | Сүздә [М] авазын дөрес әйтергә, танырга, М, м хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә, икмәккә сак караш булдыру.<br>Сузыктан соң килгән тартык [Й] авазы, ы, й хәрефләре белән белдерелгән калын ый сузыгын дөрес әйтергә, укырга. | | |
| 16. | [О] авазы, О, о хәрефләре<br>[П] авазы, П, п хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Калын сузык [О] авазы, О, о хәрефләре белән танышу, дөрес әйтү, китаптан сүзләр, җөмләләрне уку.<br>75-78 битләр. | Сүздә [О] авазын дөрес әйтергә, танырга, О, о хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. [П] авазы, П, п хәрефләрен таный, алар белән | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Чыпчык сүзен анализлау, [б-п] авазларын чагыштыру, [П] авазына характеристика бирү, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш. 79-82 битләр. | сүзләр, җөмләләр укый белергә. | | |
| 17 | [З] авазы,<br>З, з хәрефләре<br>[Ө] авазы,<br>Ө, ө хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Яңгырау тартык [З] авазы, З, з хәрефләре белән танышу, з-с авазларын чагыштыру, [З] авазына характеристика бирү, кисмә хәрефләр белән эш, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләү. 83-86 битләр.<br>Нечкә сузык [Ө] авазы, Ө, ө хәрефләре белән танышу, [о-ө] авазларын чагыштыру, [Ө] авазына характеристика бирү, кисмә хәрефләр белән эш, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләү. 87-90 битләр. | [З] авазын дөрес әйтергә, ишетеп таныргa, сүзләр, текст укый белергә, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү. Сүздә [Ө] авазын дөрес әйтергә, таныргa, Ө, ө хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. Ө хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә булуын белергә. | | |
| 18 | [ң] авазы,<br>ң хәрефе | 1 | Яңа белемб ирү | Тартык [ң] авазын дөрес әйтергә, сүздә ишетеп таныргa өйрәнү. ң хәрефе белән сүзләр уку, кисмә хәрефләр белән эш, рәсем эчтәлеген сөйләү, текст уку. 91-92 битләр. | Сүздә [ң] авазын дөрес әйтергә, таныргa, ң хәрефе белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. | | |
| 19 | Я, я хәрефләре, аларның аваз мәгънәләре Ю, ю хәрефләре, аларның аваз мәгънәләре | 1 | Яңа белем бирү | Схема буенча оя сүзен анализлау, Я, я хәрефләре белән танышу, аларның аваз мәгънәләрен ачыклау, рәсем эчтәлеге буенча әңгәмә, текст уку. 93-96 битләр. Схема буенча аю сүзен анализлау, Ю, ю хәрефләре белән танышу, аларның аваз мәгънәләрен ачыклау, рәсем эчтәлеге буенча әңгәмә, текст уку. 97-98 битләр. | Я хәрефенең нечкә һәм калын сүзләрдә ничек укылуын белергә, дөрес итеп сүзләр, җөмләләр укырга.<br>Ю хәрефенең нечкә һәм калын сүзләрдә ничек укылуын белергә, дөрес итеп сүзләр, җөмләләр укырга. | | |
| 20 | Ирен-ирен [w], ирен-теш [в] авазлары, В, в хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | Тавык сүзен анализлау. Ирен-ирен [W] авазын, ирен-теш [В] авазын дөрес әйтергә өйрәнү, кушылмаларны, сүзләрне, җөмләләрне, текст уку, рәсем буенча эчтәлек сөйләү.99-102 битләр. | Ирен-ирен [W] авазын, ирен-теш [В] авазын дөрес әйтергә,В, в хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. | | |
| 21. | [Х] авазы,<br>Х, х хәрефләре<br>[Ф] авазы, Ф, ф хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | [Х] авазы, Х, х хәрефләре белән танышу, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш.<br>103-104 битләр.<br>[Ф] авазы, Ф, ф хәрефләре белән танышу, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш.<br>105-106 битләр. | [Х] авазын дөрес әйтергә, ишетеп таныргa, сүзләр, текст укый белергә.<br>Сүздә [Ф] авазын дөрес әйтергә, таныргa, Ф, ф хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә. | | |
| 22. | ь хәрефе булган сүзләрне уку | 1 | Яңа белем бирү | ь хәрефе белән танышу, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш. 107-108 битләр. | ь хәрефе булган сүзләрне укый белергә. | | |
| 23 | [ж] авазы, Ж, ж | 1 | Яңа | [Ж] авазы, Ж, ж хәрефләре белән танышу, | [ж] авазын дөрес әйтергә, ишетеп таныргa, | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрефләре<br>[ж] авазы, Ж, җ хәрефләре | | белем бирү | схема буенча эш, рәсем эчтәлеге буенча җөмлә, текст уку.<br>109-110 битләр.<br>[ж] авазы, Ж, җ хәрефләре белән танышу, җиләк сүзен анализлау, кушылмалар, сүзләр, текстлар уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш.<br>111-112 битләр. | сүзләр, текст укый белергә.<br>Җ хәрефенең нечкә һәм калын сүзләрдә ничек укылуын белергә, дөрес итеп сүзләр, җөмләләр укырга | | |
| 24 | [һ] авазы, Һ,һ хәрефләре<br>[ц] авазы, Ц, ц хәрефләре | 1 | Яңа белем бирү | [һ] авазы, Һ,һ хәрефләре белән танышу, кушылмалар, иҗекләр, сүзләр, җөмләләр уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш.<br>113-114 битләр.<br>[ц] авазы, Ц, ц хәрефләре белән танышу, сүзләр уку, текст уку, җөмләләр уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү, кисмә хәрефләр белән эш.<br>115 битләр. | Сүздә [һ] авазын дөрес әйтергә, танырга, Һ,һ хәрефләре белән сүзләр, җөмләләр укый, рәсем эчтәлеген сөйли белергә<br>[ц] авазын дөрес әйтергә, ишетеп танырга, сүзләр, текст укый белергә | | |
| 25. | [щ] авазы, Щ, щ хәрефләре Ъ хәрефе булган сүзләрне уку. | 1 | Яңа белем бирү | [щ] авазы, Щ, щ хәрефләре белән танышу, схема буенча эш, текст уку, кисмә хәрефләр белән эш. 116 битләр.<br>Ъ хәрефе белән танышу, текст уку, рәсем эчтәлеген сөйләтү. | [щ] авазын дөрес әйтергә, ишетеп танырга, сүзләр, текст укый белергә.<br>Ъ хәрефе булган сүзләрне укый белергә. | | |
| 26. | Разил Вәлиев. Әлифба | 1 | Яңа белем бирү | Шигырьне уку, сорауларга җавап бирү. | Шигырьне сәнгатьле итеп укый белергә. | | |
| 27 | Г.Тукай. Әлифба. Р.Вәлиев. Беренчеләр | 1 | Яңа белем бирү | Шигырьләрне уку, сорауларга җавап бирү.<br>12-13 битләр | Шигырьне дөрес интонация белән укый белергә. | | |
| 28 | Мактанчык каз. Татар халык әкияте. | 1 | Яңа белем бирү | Әкият белән танышу, яхшы сыйфатлар тәрбияләү өстендә эш. 22 бит | Сорауга тулы җаваплар бирә бел, аңлаешлы һәм йөгерек итеп укый белергә. | | |
| 29. | Бари Рәхмәт. Яз килә. | 1 | Яңа белем бирү | Шигырьне уку, сорауларга тулы җаваплар бирү өстендә эш. 38 бит. | Яз турында сөйли белергә. | | |
| 30. | Ш. Галиев. Танышмак өчен табышмак. | 1 | Яңа белем бирү | Шигырьне уку, яраткан хайванның турында сөйләү.<br>46-48 битләр. | Хайваннарны ничек чакырырга кирәклекне белергә, аларны яратырга. | | |
| 31. | Г.Тукай. Бала белән күбәләк | 1 | Яңа белем бирү | Шагыйрь турында белгәннәреңне сөйләү, шигырьне кара-каршы сөйләшү итеп уку, күбәләкләр турында мәгълүмат алу.57-58 бит.. | Шигырьне сәнгатьле итеп укый белергә. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 32.-33. | Идрис Туктар. Өлгер<br>Ш. Галиев. Светофорның өч сүзе<br>Йомгаклау | 1 | Яңа белем бирү | Хикәяне рольләргә бүлеп уку, кыскача эчтәлеген сөйләргә өйрәнү. 67-68 битләр.<br>Шигырьне сәнгатьле итеп уку, эчтәлеген аңлау өстендә эш.<br>75-77 битләр | Хикәяне рольләргә бүлеп укый белергә Светофорга карап йөрергә, юл йөрү кагыйдәләрен үти белергә. | | |

**2 класс татар теле**

2класс татар теле

АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Укыту-тәрбия бирү методлары, алым, форма һәм технологияләре ничаклы һәм ничә тапкыр үзгәрсә дә, ал арның нигезе — туган тел үзгәрешсез, универсаль чара булып кала. Гасырлар уза, буыннар алмашына, ә тел һаман мәгърифәткә һәм кешенең рухи үсешенә хезмәт итә. Тел милләтне уртак максатлы тормыш эшчәнлеге һәм аралашу мохитенә берләштерә. Кеше шул эшчәнлектә һәм мохиттә катнашып һәм аралашып тәрбияләнә, аң-белемен үстерә һәм үзендә чын кеше сыйфатлары булдыра.

Шәхес — тел һәм мәдәният бәйләнеше үзәге, шуңа күрә телдә гәүдәләндерелгән шәхес турында гына сүз алып барырга мөмкин. Бала тел аша тирә-якны өйрәнә һәм үзен башкалар арасында таныта. Халык үз фәлсәфәсендә телнең әһәмиятен бик төгәл бәяләгән: «Теле бар,— димәк, кеше».

Тел дәресләре балаларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтләрен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерергә тиеш.

Мәктәпкә кергәнче үк, бала ана телендә сөйләшә белә, ләкин ул телне әле аңлы рәвештә кулланмый, татарча сөйләү — аның өчен табигый хәл. Башлангыч мәктәпнең бурычы — укучыларны ана телен төшенеп, аңлап, закончалыкларына таянып һәм сөйләм ситуацияләренә туры китереп кулланырга өйрәтү. Моның өчен сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен дә (тыңлап аңлау, сөйләшү һәм сөйләү, уку һәм язу) үстерергә кирәк. Дәреслекләрдә материал коммуникатив юнәлешле итеп, ә укучыларның танып белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла.

Укытуның эчтәлеге һәм методикасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлтелә:

Укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм телне аралашу чарасы буларак барлык ситуацияләрдә кулланырга өйрәтү;

аралашу һәм танып белү чарасы буларак телне аңлы үзләштерүгә ирешү;

балаларны текст ,китап белән эш итү алымнарына өйрәтү;

коммуникатив

сөйләм осталыгы һәм иҗади сәләт арасында бәйләнеш булдыру;

Моның өчен тел дәресләрен танып белүгә юнәлешлеитеп, балаларның актив эшчәнлегенә таянып оештырырга кирәк.

Һәр тема түбәндәге эзлеклелектә өйрәтелә:

сөйләмне, текстны тикшереп, өйрәнеләчәк  теманың әһәмияте күрсәтелә, проблема куела;
укучылар үзләре «ачкан» кагыйдәне, төшемчәне**,** эш алымын мөстәкыйль рәвештә әйтәләр;
дәреслекләргә таянып, укучылар тарафыннанясалган ачышларга төгәллек һәм тулылык кертелә;
тема буенча алган белемнәрне куллануга күнегүләрүткәрелә.

Эшнең шушындый эзлеклелектә оештырылуы телне аңлауда эчтәлектән формага күчәргә мөмкинлек бирә, икенче төрле әйткәндә, лексикадан грамматикага, фонетикадан грамматикага, сөйләмнән телгә, телдән сөйләмгә, аралашу ситуациясендә әйтелгәнне аңлаудан үз сөйләмеңне мөстәкыйль рәвештә төзүгә салмак күчеш ясарга мөмкинлек бирә.

**Башлангыч сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

**Укучылар түбәндәгеләрне белергә тиеш:**

сөйләмдәге авазлар;
өйрәнелгән сүз төркемнәренең лексик һәм грамматик
билгеләре;
сүзнең мәгънәле кисәкләре;
гади һәм кушма җөмлә, җөмләдә баш һәм иярчен кисәкләрнең (терминнарын әйтмичә) билгеләре;
сүзтезмә билгеләре.

Укучылар чагыштыра һәм аера белергә тиеш:

аваз һәм хәреф;
сузык һәм тартык авазлар;
калын һәм нечкә сузыклар;
яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар;
исем, сыйфат, фигыль, зат алмашлыклары, кисәкчә;
тамыр һәм кушымча, сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч
кушымчалар;
җөмләләрнең әйтелү максаты буенча төрләре**;**җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре (төрләргә бчрпшчә**);** җөмлә белән сүзтезмәнең аермасы; тиңдәш кисәкле җөмләләр.

**Укучыларда түбәндәге эш осталыгы булырга тиеш:**

сүзләрне иҗеккә бүлү;

сүздә аваз һәм хәреф санын чагыштыру;

еш кулланышлы сүзләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтү;

алфавитны куллана белү (сүзлек, каталог белән эш);

сүзләрне юлдан юлга күчерү;

өйрәнелгән сүз төркемнәренең җөмләдәге ролен күрсәтү;

сүзнең мәгънәле кисәкләрен һәм ясалышын билгеләү;

сүздәге ясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны билгеләү;

фигыльләрдәге зат-сан кушымчаларын аеру;

җөмләдәге сүзләр бәйләнешен ачыклау;

гади җөмләдә тиңдәш кисәкләрне табу;

75—80 сүзле текстны ачык һәм төгәл итеп күчереп һәм ишетеп язу.

Түбәндәге орфограмма һәм пунктограммалар кертелә:

җөмлә башында һәм ялгызлык исемнәрдә баш хәреф;

сүзләрдә *о-ы, өе* сузыклары;

ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләр;

кушма һәм парлы сүзләр;

саңгырау яки *б, в, г, д* тартыкларына беткән исемнәрдә килеш кушымчалары;

борын авазларына беткән исемнәрдә килеш кушымчалары;

сыйфатларда чагыштыру, артыклык һәм кимлек дәрәҗәсе формаларының язылышы;

җөмлә ахырында тыныш билгеләре (нокта, сорау һәм өндәү билгеләре);

тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

## Сүзлек диктанты өчен якынча нормалар

| Сыйныф | Сүз саны |
|---|---|
| II | 8—10 |
| III | 10—12 |

## Контроль диктант өчен нормалар

| Сыйныф | I яртыеллык | II яртыеллык |
|---|---|---|
| I | 25—30сүз | 15—17 сүз |
| II | 45—50 сүз | 35—40 сүз |
| III | 65—70 сүз | 55—60 сүз |

изложение өчен текстларның күләме һәр сыйныфта 15—20 сүзгә артыграк була.

.

### 2 нче сыйныф

### ФОНЕТИКА, ГРАММАТИКА, ДӨРЕС ЯЗУ ҺӘМ СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ

#### Авазлар һәм хәрефләр

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар һәм аларның хәрефләре. *Э, о, ө, е, ю, я* хәрефләрен сүздә дөрес язу кагыйдәләре.

Иҗекләр. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Иҗек төзүдә сузык авазның әһәмияте. Язу юлы ахырына сыймаган сүзләрне бүлеп күчерүдә иҗекнең роле.

Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар. Парлы тартык авазлар. Парсыз тартык авазлар. Тартык авазларны хәрефләр белән белдерү. Сүздә й, *в, к, г* һәм *м, л, н, ң, х, һ* хәрефләрен язу һәм шул хәрефләр булган сүзләрне дөрес уку. Гади сүзләрдә янәшә килгән бертөрле аваз хәрефләрен төшереп калдырмыйча язу *(мәхәббәт, эссе)* һ. б.

Калынлык, нечкәлек һәм аеру билгеләре буларак *ъ,* ъ хәрефләрен куллану үрнәкләре белән таныштыру, шул хәрефләр булган сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Алфавит. Алфавитны белүнең әһәмияте. Татар алфавитында хәрефләрнең урнашу тәртибе, алар белдергән авазлар һәм хәреф исемнәре. Бирелгән сүзләрне, беренче хәрефләренә карап, алфавит тәртибендә язу. Укучылар өчен чыгарылган орфография сүзлегеннән файдалана белү.

**Сүз**

Сүз җирлеге. Предмет, билге, хәрәкәт һәм сүз. Авазлар һәм сүз. Иң кыска сүз *(у, и, ә).*

Сүз тамыры. Сүзләрнең тамырлары белән таныштыру. Татарча сүзләрдә сүзнең тамыры сүз башында булуын, үзгәрмәвен, барлык кушымчаларның шуларга сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен гамәли күзәтү *(эш: эшле, эшсез, эшлә, эшчән, эшлекле).*

Предметларны атаган һәм кем? нәрсә? сорауларына җавап биргән сүзләр. Предметларның билгеләрен белдергән һәм нинди? кайсы? сорауларына җавап биргән сүзләр. Предметларның эшен, хәрәкәтен белдергән һәм нишли? нишләр? Кебек сорауга

Җавап биргән сүзләр. Шул сүзләрне, сораулар куеп.җөмлә эченнән таба белү.

Кеше исемнәрендә,фамилияләрдә,йорт хайваны кушаматларынды,шәһәр,авыл,елга исемнәрендә баш хәреф.

**Җомлә**

Сойләмие җөмләләргә аеру. Җомләдә сүзнең кем һәм нәрсә и турында баруын курсәткән һәм алар үтәгән эшне белдергән сүзләрне табу. Җөмлә төзүче баш кисәләр (ия, хәбәр) белән таныштыру. Сораулар ярдәмендә җөмләдәнсүзләр бәйләнешен

билгеләү. Җөмләләрнең мәгънәви- интонационүзенчәлекләрен күзәтү һәм җөмлә ахырымда сорау,өндәү билгеләрен кую, җөмләләр төзү. Дәрестәтикшергән җөмләләрне ишетеп язу. Җөмләдәге им бетлән хәбәрне сызыклар белән билгеләтү.

## Бәйләнешле сөйләм

Сөйләм. Сөйләмнең кешеләр тормышындагы әһәмияте. Әйтеп һәм язып аралашу үзенчәлекләрен гамәлдә күзәтү.

Текст. Тексттагы терәк сүзләрне аерып күрсәтү. Бер темага берләштерелгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыру. Текст темасын билгеләү. Текстны кисәкләргә бүлү. Зур булмаган текстка һәм текст кисәкләренә исем уйлап табу.

Изложение. Берәр әсәрне укып, кыскача аның эчтәлеген үз сүзләрең белән язу. Бирелгән сораулар буенча укытучы җитәкчелегендә инша язу. Сюжетлы рәсемнәргә карап, сораулар ярдәмендә мәгънәви эзлекле бәйләнгән җөмләләр төзү һәм шул җөмләләрне язып кую.

Сочинение. Укучыларның күмәк э!пләре, уеннары, төрле шөгыльләре (чана шуу, җиләккә бару, бакчада эшләү һ. б.) турында үз ихтыярлары белән сөйләүләрен оештыру, телдән хикәяләү. Тора-бара кайберләрен бергәләп язып та кую.

Әдәпле сөйләшү. Кешеләр белән очрашканда, танышканда, каршы алганда, озатканда, саубуллашканда кулланылган сүзләр, рәхмәт әйтү, гафу үтенү һәм мөрәҗәгать итүләр. Уку елы дәвамында шул күнекмәләрне булдыру, шуңа гадәтләндерү өстендә өзлексез эшләү.

## Матур язу

Язу гигиенасы кагыйдәләрен ныгыту: язганда дөрес утыру, дәфтәрне сул якка авыш итеп кую, ручканы дөрес тоту һ. б.

Хәрефләрнең формалары, сүздә хәрефләрне тоташтырган сызыклар өстендә эшләү. Язылышы катлаулана бару тәртибендә юл һәм баш хәрефләрне төркемләп язу:

1)*и, ш, у, й, И, Ш, Й; г, п, т, р, һ;*
2)*л,җЛ,М,А,я, Я; 3)у,ц,щ,У,у,Ч,ч,Ц,Щ;*

4)*с, С, ә, Ә, э, Ә, е, Е; о, О, ө, Ө, а, д, б;*

5)*ъ, ы, ъ, в, Ы;*

6)*н, ң, ю, һ, Н, Ю, к, К; 7)з,З, В, х, Х, ж, Ж, җ, Җ, ф; 8)Ф,Г,П,Т,Б,Р,Д.*

Юлы бер сызыклы дәфтәргә язу күнегүләре. *Ил, ит, ул, еш, ди, эз, илә, әти, үтә* кебек өзмичә язылучы юл хәрефләреннән торган сүзләрне язу күнегүләре. Формаларында, тоташтыргыч сызыкларында кимчелекләр еш булган баш *П, Т, Р, Җ, У, Д, Я, Н, К, Ф* һәм юл *з, д, б, в* һ. б. хәрефләрне язу.

Җөмләләрдәге сүзләрне тоташ ритмик язу күнегүләре.

Дөрес әйтелеше, язылышы уку елы дәвамында гамәли үзләштерелергә тиешле сүзләр:

*аваз, авыз, авыл, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт, гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмбе, елга, җавап, җиңел, җиңү, җомга, җөмлә, җылы, йолдыз, йөрәк, караңгы, көньяк, кыңгырау, маңгай, Мәскәү, муен, онык, оя, пәнҗешәмбе, савыт, сәгать, сәлам, сеңел, сишәмбе, тавык, тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш, хайван, хөрмәт, һава, һаман, чаңгы, чәршәмбе, чия, шәһәр, шуа, эссе, юан, якшәмбе^*

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр**

IIсыйныфны тәмамлаганда, укучылар белергә тиеш:

Сүзләрне, җөмләләрне, 35—40 сүзле текстны, хәрефен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алмаштырмыйча, каллиграфик дөрес язу.

Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм иҗекләп юлдан юлга дөрес күчерү, еш кулланыла торган сүзләрдә нечкә тартыкларны яки иҗекләрне сузык аваз хәрефләре *(кадер, гадәт)* яки нечкәлек билгесе *(пальма, пакь)* белән күрсәтү.

Кеше исемнәрен, фамилияләрне, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

*Э, е, о, ө, я, ю, в, к, г, й, н, ң, х, һ* хәрефләре, *ый, йо, йә* кушылмалары булган сүзләрне дөрес язу.

Янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефе булган *әллә, кәккүк, Саттар, Габбас* кебек сүзләрне, нечкә, калын, аеру билгесе булган гади сүзләрне *(дөнья, алъяпкыч)* һәм IIсыйныф программасында бирелгән сүзләрне дөрес язу.

Сүзгә фонетик анализ ясау: иҗекләргә бүлү, авазларны һәм хәрефләрне сүздәге тәртиптә күрсәтү, *альбом, вәгъдә, юл, яр, еш* тибындагы сүзләрнең аваз һәм хәреф санын дөрес әйтү һәм аларның әйтелеше белән язылышы арасындагы мөнәсәбәтне дөрес билгеләү.

Сүзләргә сораунысдөрес кую һәм сораулар буенча предметны, предметның билгесен, эшен һәм хәрәкәтен белдергән сүзләрне таба белү. Кем? нәрсә? соравына җавап биргән сүзләрне бер-берсеннән аера белү.

Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләү һәм җөмләнең баш кисәкләрен табу; җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау, өндәү билгеләрен куеп яза белү.

Сораулар ярдәмендә 30—45 сүзле текстка изложение язу, ирекле темага (бакчада эшләү, җиләккә бару, йорт кошларын карау) 4—5 җөмлә төзеп сөйләү һәм шуны язып кую.

| | Дәрес темасы | С.саны | Дәреснең тибы | Максат | таләпләр | Өй эше | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | **1 чирек.**<br>Авазлар һәм хәрефләр. | 1с | Яңа белем үзләштерү дәресе | Балаларга сүз һәм аваз турында беренче мәгълүмәт бирү, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү, яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру, картинага карап хикәяләүгәөйрәтүне дәвам итү. | **2 классны тәмамлаганда укучылар белергә тиеш:**<br><br>Сүзләрне, җөмләләрне, 30-45 сүзле текстны, хәрефне бозмыйча, төшереп калдырмыйча, | | | |
| 2. | Сузык һәм тартык авазлар.Сузык авазлар.Калын сузыклар.<br>Нечкә сузыклар.Тартык авазлар. | 2с | | Балаларга сузык һәм тартык авазлар турында беренче мәгълүмәт бирү | | | | |
| | | | Ныгыту дәресе | Сузык һәм тартык авазлар белән таныштыру.<br>Сүзгә фонетик анализ ясарга өйрәтү. | | | | |
| | | | Яңа белем | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | О хәрефе. | 2с | үзләштерү дәресе | Э, е., о, ө, ый, йо, йө, я, ю хәрефләре булган сүзләрне дөрес язарга өйрәтү, балаларда татар теленә мәхәббәт, бер-берсенә ихтирам тәрбияләү, үткән дәрестә өйрәнелгән фразаларны истә калдыру эшен дәвам итү, укытучы үрнәгендә җөмләләрне кабатлап әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. | алмаштырмыйча һәм хәреф өстәмичә, каллиграфик дөрес язу.<br><br>Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм иҗекләп юлдан юлга дөрес күчерү.<br><br>Еш кулланыла торган сүзләрдә нечкә тартыкларны яки иҗекләрне сузык хәрефләре һәм нечкәлек | | | |
| 4. | О-ы хәрефләре.Ө хәрефе. | 2с | Ныгыту дәресе | | | | | |
| | | | Яңа белем үзләштерү дәресе | | | | | |
| 5. | Ө-е хәрефләре. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 6. | Э-е хәрефләре.Э хәрефе кергән сүзләр. | 2с | Яңа белем үзләштерү дәресе | | | | | |
| 7. | | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 8. | О, ө, э хәрефләрен кабатлау.<br>Мөстәкыйль эш. | 2с | Кабатлау дәресе | | | | | |
| | | | Булган белемнәрне тикшерү | | | | | |
| 9. | Иҗек. | 1с | Яңа белем үзләштерү дәресе | Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм иҗекләп юлдан юлга дөрес күчерергә өйрәтү. | | | | |
| 10. | Сүзләрне бер юлдан икенче юлга күчерү. | 2с | | | | | | |
| 11. | Тартык авазлар.<br>Тартык авазларның бүленеше.М,Н,Ң хәрефләре | 2с | Яңа белем үзләштерү дәресе | Авазларның артикуляциясе чагыштырыла, сүзләргә аваз-хәреф һәм иҗек анализы ясау күнекмәләре ныгытыла. | билгесе белән күрсәтү.<br><br>Кеше исемнәрен, фамилияләрне, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.<br><br>Э, е, о, ө, ый, йо, йө, я, ю хәрефләре булган сүзләрне дөрес язу. | | | |
| | | | Ныгыту дәресе | В, к, г, й, н, ң хәрефләре булган сүзләрне дөрес язарга өйрәтү, балаларда татар теленә мәхәббәт, бер-берсенә ихтирам тәрбияләү, үткән дәрестә өйрәнелгән фразаларны истә калдыру эшен дәвам итү, укытучы үрнәгендә җөмләләрне кабатлап әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. | | | | |
| 12. | Тартык авазлар, [W] авазы.<br>Тартык авазлар, [W], [в] авазлары. | 2с | Яңа белем үзләштерү дәресе | | | | | |
| | | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 13. | К хәрефе, [къ] авазы. | 1с | Яңа белем үзләштерү дәресе | | | | | |
| 14. | К хәрефе, [къ], [к] авазлары. | 1с | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 15. | Г хәрефе, [гъ], [г] авазлары. | 2с | Яңа белем | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16. | Х, hхәрефләре. | 2с | үзләштерү дәресе | | | | | |
| 17. | Й хәрефе. | 1с | | | В, к, г, й, н, ң хәрефләре булган сүзләрне дөрес язу.<br><br>Янәшә килгән бертөрле тартык булган сүзләрне дөрес язу.<br><br>Нечкә һәм калын аеру билгесе булган гади сүзләрне дөрес язу.<br><br>Сүзгә фонетик анализ ясау.<br><br>Сүзләргә сорауларны дөрес куя һәм шул сораулар буенча предметны, предмет билгесен, аның эшен һәм хәрәкәтен белдергән сүзләрне таба белү, кем? Соравына җавап булган сүзләрне нәрсә? Соравына җавап булган сүзләрдән аера белү. | | | |
| 18. | Контроль диктант. | 2с | Булган белемнәрне тикшерү | Укучыларның белемен, күнекмә һәм дөрес яза белүләрен тикшерү һәм өлгерешен исәпләү.<br>Диктантны укучылар белән бергә җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 1-2 | **2 чирек.**<br>Е, я, ю хәрефләре. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Е, ю, я хәрефләре булган сүзләрне дөрес язарга өйрәтү, балаларда татар теленә мәхәббәт, бер-берсенә ихтирам тәрбияләү, үткән дәрестә өйрәнелгән фразаларны истә калдыру эшен дәвам итү, укытучы үрнәгендә җөмләләрне кабатлап әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. | | | | |
| 3-4 | Е хәрефе. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 5 | Я хәрефе. | | | | | | | |
| 6 | Ю хәрефе. | | | | | | | |
| 7 | Үткән хәрефләрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | | | | | |
| 8 | Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Сүзгә фонетик анализ ясарга өйрәтү. | | | | |
| 9 | Бертөрле тартыкларның янәшә килүе. | | | Янәшә килгән бертөрле тартык булган сүзләрне дөрес язарга өйрәтү. | | | | |
| 10-11. | Тавышсыз ь хәрефе. | | | Тавышсыз хәрефләрнең калынлык, нечкәлек һәм аеру функцияләрендә куллану үрнәкләре белән таныштыру. Еш кулланыла торган сүзләрдә нечкә тартыкларны яки иҗекләрне сузык хәрефләре һәм нечкәлек билгесе белән күрсәтү. | | | | |
| 12 | Тавышсыз ь хәрефе. Күчереп язу. | | Ныгыту дәресе | Нечкә һәм калын аеру билгесе булган гади сүзләрне дөрес язарга өйрәтү. | | | . | |
| 13 | Ъ хәрефе. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 14 | Е, я, ю хәрефләрен кабатлау. | | Кабатлау дәресе | Е, ю, я хәрефләре булган сүзләрне дөрес язарга өйрәтү. | | | | |
| 15 | Янәшә килгән бертөрле | | Кабатлау дәресе | Янәшә килгән бертөрле тартык булган сүзләрне дөрес язарга өйрәтү. | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тартыкларны кабатлау. | | | | | | | |
| 16 | Тавышсыз хәрефләрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | Нечкә һәм калын аеру билгесе булган гади сүзләрне дөрес язарга өйрәтү. | Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләү һәм җөмләнең баш кисәкләрен табу.<br><br>Җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау, өндәү билгесе кую.<br><br>Сораулар ярдәмендә 30-45 сүзле текстка изложение язу.<br><br>Бирелгән темага 2-3 җөмлә төзү һәм язып кую. | | | |
| 17 | Алфавит. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Алфавитны белүнең әһәмиятен аңлату, татар алфавитында хәрефләрнең аваз мәгънәләре һәм исемнәре белән таныштыру, беренче хәрефкә карап, дәреслектәге сүзлекчәдән алфавит тәртибендә сүзләрне табарга өйрәтү, бирелгән сүзләрне, беренче хәрефләренә карап, алфавит тәртибендә язарга өйрәтү. | | | | |
| 18 | Сүзләрне алфавит тәртибендә язу. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 19 | Контроль диктант. | | Булган белемнәрне тикшерү | Укучыларның белемен, күнекмә һәм дөрес яза белүләрен тикшерү һәм өлгерешен исәпләү. | | | | |
| 20 | Хаталар өстендә эш. | | Кабатлау дәресе | Диктантны укучылар белән бергә җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 21 | Үткәннәрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү, яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру. | | | | |
| 1. | **3 чирек**.<br>Сүз. Сүзнең тамыры. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Сүзнең тамыры белән таныштыру. Тамырдаш гади сүзләрнең тамыры сүз башында килеп, бертөрле язылуын күзәтү. | | | | |
| 2. | Тамырдаш сүзләр. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 3. | Кушымчалар. | | Ныгыту дәресе | Кушымчалар белән таныштыру. Сүзне төзелеше ягыннан тикшерергә өйрәтү. Нечкә һәм калын аеру билгесе булган гади сүзләрне дөрес язарга өйрәтү. Кушымчаларның төркемнәре белән таныштыру. Аларның аермаларын күрсәтү. | | | | |
| 4. | Калын һәм нечкә кушымчалар.<br>Сүз ясагыч кушымчалар. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | | | | | |
| 5. | Сүз төрләндергеч кушымчалар. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 6. | Диктант. | | Булган белемнәрне тикшерү | Укучыларның белемен, күнекмә һәм дөрес яза белүләрен тикшерү һәм өлгерешен исәпләү. | | | | |
| 7. | Хаталар өстендә эш. | | Кабатлау дәресе | Диктантны укучылар белән бергә | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 8. | Предметны белдерә торган сүзләр. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Предметларны атаган һәм кем? Нәрсә? Сорауларына җавап булган сүзләр белән таныштыру. Шул сүзләрне, сораулар куеп, җөмлә эчендә табарга өйрәтү. Исемнәрне мәгънә ягыннан төркемнәргә бүлергә өйрәтү. | | | | |
| 9. | “Исем” термины, аның сораулары. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 10. | Мәгънәләре буенча исемнәрне төркемләү. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 11. | Кешене белдергән сүзләр | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 12. | Исемнәрне мәгънә ягыннан төркемнәргә бүлү. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 13. | Исем һәм фамилияләрдә баш хәреф. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Балаларга кеше исемнәрендә һәм фамилияләрдә баш хәреф турында беренче мәгълүмәт бирү, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү, яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру, картинага карап хикәяләүгәөйрәтүне дәвам итү. | | | | |
| 14. | Ил, шәһәр, авыл исемнәрендә баш хәреф. | | Ныгыту дәресе | Кеше исемнәрен, фамилияләрне, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язырга өйрәтү. | | | | |
| 15. | Елга, күл исемнәрендә баш хәреф. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 16. | Хайван кушаматларында баш хәреф. | | Ныгыту дәресе | Балаларга кеше исемнәрендә һәм фамилияләрдә, хайван кушаматларында баш хәреф турында беренче мәгълүмәт бирү | | | | |
| 17. | Исем турында үткәннәрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | Предметларны атаган һәм кем? Нәрсә? сорауларына җавап булган сүзләр белән таныштыру. Шул сүзләрне, сораулар куеп, җөмлә эчендә табарга өйрәтү. | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Исемнәрне мәгънә ягыннан төркемнәргә бүлергә өйрәтү. | | | | |
| 18. | Искәртмәле диктант. | | Булган белемнәрне тикшерү | Язганда укучы хата җибәриәсен өчен, төрле юллар белән хата язу ихтималын язганчы ук бетереп кую. | | | | |
| 19-20 | Хаталар өстендә эш. | | Кабатлау дәресе | Диктантны укучылар белән бергә җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 21-22 | Билгене белдерә торган сүзләр. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Предметларның билгеләрен белдергән һәм нинди? Кайсы? сорауларына җавап булган сүзләр белән таныштыру. Шул сүзләрне, сораулар куеп, җөмлә эчендә табарга өйрәтү. | | | | |
| 23-24 | Предметның билгесен белдерә торган сүзләрне төркемләү. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 25 | Нинди? Кайсы? Сорауларына җавап булган сүзләр. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 26-27 | Сыйфат турында үткәннәрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | | | | | |
| 28 | Контроль диктант. | | Булган белемнәрне тикшерү | Укучыларның белемен, күнекмә һәм дөрес яза белүләрен тикшерү һәм өлгерешен исәпләү. | | | | |
| 29 | Хаталар өстендә эш. | | Кабатлау дәресе | Диктантны укучылар белән бергә җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 0. | Үткәннәрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү, яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру. | | | | |
| 1 | **4 чирек.**<br>Эшне белдерә торган сүзләр. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Предметларның эшен, хәрәкәтен белдергән һәм нишли? Нишләде? Нишләр? кебек сорауларына җавап булган сүзләр белән таныштыру. Шул сүзләрне, сораулар куеп, җөмлә эчендә табарга өйрәтү.<br>Фигыльләрнең барлык-юклык формалары | | | | |
| 2-3 | Нишли? Нишләде? сорауларына җавап бирә торган сүзләр. | | Ныгыту дәресе | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4-5 | Эшне, хәрәкәтне белдергән сүзләргә сораулар кую. | | Ныгыту дәресе | турында төшенчә бирү. | | | | |
| 6-7 | Фигыльнең белән танышу. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 8-9 | Фигыльләрне төркемнәргә бүлү. | | Ныгыту дәресе | | | | | |
| 10-11 | Рәсем буенча хикәя төзү. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Картинага карап хикәяләүгә өйрәтүне дәвам итү, сөйләм үстерү. | | | | |
| 12 | Хаталар өстендә эш. | | Кабатлау дәресе | Хикәяне укучылар белән бергә җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 13 | Җөмлә турында төшенчә. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | балаларга җөмлә турында беренче мәгълүмәт бирү, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү, яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру, картинага карап хикәяләүгә өйрәтүне дәвам итү, | | | | |
| 14-15 | Җөмлә төрләре. | | Ныгыту дәресе | Сөйләмне барлыкка китерүдә җөмләнең әһәмиятен аңлату. Төрле интонация белән | | | | |
| 16 | Җөмләдә баш кисәкләр. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, сүзләр арасындагы бәйләнешне аңлату.Җөмләдә сүзнең кем яки нәрсә турында баруын һәм алар турында нинди яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләрне күрсәтү. | | | | |
| 17 | Изложение. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Сораулар ярдәмендә 30-45 сүзле текстка изложение язарга өйрәтү. | | | | |
| 18 | Хаталар өстендә эш. | | Кабатлау дәресе | Иншаны укучылар белән бергә җентекләп тикшерү.<br>Хаталарны төзәтү.<br>Охшаш бүтән текстны яздырту. | | | | |
| 19-20 | Җөмләдә сүзләрнең бәйләнеше. | | Яңа белем | Җөмләдә сүзләрнең бәйләнеше. Җөмләләрдән кем һәм нәрсә турында әйтелгәнне | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | үзләштерү дәресе | күрсәткән, аларның нишләгәнен белдергән сүзләрне табарга өйрәтү. | | | | |
| 21 | Сөйләм һәм текст. | | Яңа белем үзләштерү дәресе | Балаларга сөйләм турында беренче мәгълүмәт бирү, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү | | | | |
| 22 | Текстның төп фикере, өлешләре. | | Ныгыту дәресе | Текстның төп фикере, өлешләре белән таныштыру. | | | | |
| 23 | Контроль диктант. | | Булган белемнәрне тикшерү | Укучыларның белемен, күнекмә һәм дөрес яза белүләрен тикшерү һәм өлгерешен исәпләү. | | | | |
| 24 | Ел буенча үткәннәрне кабатлау. | | Кабатлау дәресе | Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү, яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру. | | | | |

**2 класс уку**

**Эш программасы статусы**

Программа нигезенә Россия, Татарстан Мәгариф һәм фән министырлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары салынды. «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы, 1-11 сыйныфлары (татар балалары өчен),» на нигезләнеп төзелде. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011.

**Эш программасы структурасы**

Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән

**Эш программасының эчтәлеге**

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм анны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш». Бу – яңа стандарта эшлекле дип атала. Эшлекле – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. алу гамәлләрнең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.

**Гомуми бирү мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең төп максаты** – гамәли максат, ягъни телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында бирү һәм күнекмәләрне үстерү, укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт.

Тәрбияви максат балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

**Әдәби укуны укытуның максатлары:**

– матур әдәбият, аның авторы, әсәрнең жанры, персонажы турында күзаллау булдыру;
– уку күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү;
– матур әдәбият әсәрләрен укуга, китапка кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү;
– татар теленең үзенчәлекле авазларын дөрес әйтә белү;
– дөрес һәм бәйләнелешле әйтмә һәм язма сөйләмгә өйрәту
– укучыларның фикерләү сәләтен үстерү, тел чараларын аралашуның эчтәлегеннән чыгып билгели белү, балаларның ана телендә аралашу күнекмәләрен камилләштерү;
– телнең фонетика, лексика, грамматикасы буенча башлангыч алу, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә белү күнекмәләрен булдыру;
– дөрес уку һәм дөрес язу күнекмәләрен булдыру, диалогик сөйләмдә катнашу, гадирәк итеп төзелгән монологик сөйләм оештыру.

**Программада 2 нче сыйныфта әдәби укудан атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик план** ”Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” (1-11 нче сыйныфлар. – Казан: « Татарстан китап нәшрияты», 2011) нигезендә төзелде.

Укыту планы гамәлдәге базис план буенча 64 сәгать исәбеннән төзелде. 4 сәгать кабатлауга, 2 сәгать сыйныфтан тыш укуга өстәлде.

**Төп эчтәлек**

| **№** | **Программадагы темалар** | **Сәг.саны** |
|---|---|---|
| 1 | Балалар, әйдәгез мәктәпкә! | 6 |
| 2 | Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта | 6 |
| 3 | Гаилә һәм туганнар | 7 |
| 4 | Ак чәчәкләр ява | 6 |
| 5 | Үзе яхшының эше дә яхшы... | 5 |
| 6 | Туган җир, туган ил | 7 |
| 7 | Яз | 6 |
| 8 | Язучылар иҗат иткән әкиятләр | 3 |
| 9 | Әкиятләр | 6 |
| 10 | Ямьле җәй | 5 |
| 11 | Безнең якын дусларыбыз | 7 |
| 12 | Кабатлау | 4 |
| 13 | Сыйныфтан тыш уку | 2 |

| **Әсәрләрне уку һәм өйрәнү** | **Бәйләнешле сөйләм үстерү** | **Сыйныфтан тыш уку** |
|---|---|---|
| 61 | 7 | 2 |

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

Татар графикасы үзенчәлекләрен белү.
Өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү.
Тексттагы вакыйга яки төп персонаж буенча аңа исем таба белү.
Укытучының соравына тексттагы вакыйгаяки эпизод белән җавап бирә белү.
Текстның төп фикерен үзе билгели алу.
Берничә текстны темасы буенча берләштерә белү.
Укылган бүлеккә план төзи белү.
Геройларга характеристика бирү.
Автор позициясен ачыклау.
Укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү.
Әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку.
Кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану.
Өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерне белдерү.
үкыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилли белү.
Татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү.
Эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү.
Аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле белешмә әдәбият, вакытлы матбуга, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары**

**Тыңлап аңлауны бәяләү нормасы**

Тыңланган татар сөйләмен тулаем дөрес аңлап, эчтәлеген сөйли алганда, **«5»ле** куела.

Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча дөрес сөйли алганда**, «4»ле** куела.

Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген өлешчә генә сөйли алганда, **«3»ле** куела.

Тыңланган татар сөйләменең эчтәлеген тулаем аңламаганда, **«2»ле** куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү нормасы**

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, **«5»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2—3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, **«4»ле** куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4—6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә, **«3»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда, **«2»ле** куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү нормасы**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле булган монологик сөйләм өчен «5»**ле** куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2—3 хатасы булган монологик сөйләм өчен **«4»ле** куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4—6 хатасы булган монологик сөйләм өчен «3»**ле** куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог төзи алмаганда, «2»**ле** куела.

**Укуны бәяләү нормасы**

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап, авазларны һәм сүзләрне дөрес әйтеп, басымны дөрес куеп, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп тиешле тизлектә укыганда, «5»ле куела.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп, әмма тупас булмаган 2—3 орфоэпик хата җибәреп (авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, интонацияне сакламау) укыганда, «4»**ле** куела.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, 4—6 тупас орфоэпик хата җибәреп укыганда һәм уку тизлеге акрын булганда, «3»ле куела.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулысынча аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып, 7 дән артык әйтелеш хатасы җибәреп һәм уку тизлегенә куелган таләпләрне сакламыйча укыганда, «2»ле куела.

| № | Эш төрләре | II нче сыйныф |
|---|---|---|
| 1 | Тыңлап аңлау (минутларда) | 0,5—1 |
| 2 | Диалогик сөйләм (репликалар саны) | 4 |
| 3 | Монологик сөйләм (фразалар саны) | 5 |
| 4 | Уку (сүзләр саны) | 30—35 |

**Йомгаклау билгесе**

Йомгаклау билгесе чирек һәм уку елы ахырында куела. Ул, беренче чиратта, укучыларның телдән сөйләм күнекмәләре, бәйләнешле сөйләм төзи белү осталыгы, татар телендә аралаша алу мөмкинлекләреннән чыгып, шул ук вакытта язма эшләрнең нәтиҗәләрен исәпкә алып куелырга тиеш.

### Уку техникасы

Аңлап , дөрес һәм йөгерек уку.

Эчтән уку һәм сәнгатьле укуның башлангыч күнекмәләрен формалаштыру.

### Әдәби текст белән эшләү

Текстның нәрсә турында булуын аңлата белү.

Текстны вакыйгасы буенча өлешләргә тарката белү.

Укытучы ярдәмендә план төзи һәм шуның буенча эчтәлеген сөйли белү.

Укытучы яки башка кеше укыганны тыңлап, эчтәлекне сөйли белү.

### Сөйләм телен үстерү

Үзләштергән материалга нигезләнеп, ирекле сөйләшү-диалог оештыру.

Яшь үзенчәлегенә туры килердәй текст сайлау.

Бирелгән план буенча эчтәлекне сөйләү.

Иҗади эшләргә өйрәнү - хикәя, әкиятләрне дәвам итү, әкиятләр, табышмаклар уйлау.

Шигырьләр ятлау.

Сорауларга язма җаваплпр бирү.

### Әдәбият белемен өйрәнүгә әзерлек

Сүз сәнгатенең бер төре буларак матур әдәбият белән таныштыра башлау.

Халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләр.

Әдәби әсәрләрдә гомумиләштерелгән образлар, аларның эш гамәлләре.

Шигырь, аның сәнгатьлелеге.

Әкиятләрнең төп фикере, кызыклы сюжеты һәм композициясе.

Табышмак, мәкаль һәм әйтемнәр, башваткычлар.

Төрле сурәтләү чаралары белән таныштыру.

### Ятлау өчен әсәрләр

1. Г. Тукай Туган тел. Җир йокысы. Безнең гаилә. Кояш
2. Бари Рәхмәт Кошлар киткәндә.
3. М. Җәлил Көз җитте.
4. Гасыйм Лотфи Сыерчык.
5. Зәкия Туфайлова Туган ил.
6. Р. Миңнуллин Әни.
7. Ш. Галиев Рус казлары: га-га-га.

### Әңгәмә кору өчен якынча темалар

1. И туган тел, и матур тел!
2. Күркәм, әдәпле сүзләр.
3. Яшел чыршы янында.
4. Әниләр бәйрәме.
5. Без Татарстанда яшибез.
6. Яшелчә кибетендә.

**II нче сыйныфта әдәби укудан үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр**

<table>
<tr><th>Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә</th><th>Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү</th><th>Тыңлап аңлау</th><th>Телдән һәм язма сөйләм үстерү , аралаша белү</th></tr>
<tr><td rowspan="2">Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.</td><td>Дәреслек белән эш итә белү</td><td rowspan="2">Укытучының (сыйныфташның) сөйләмен ишетеп аңлау</td><td rowspan="4">Телдән сөйләм:<br>– Бирелгән ситуация, лексик тема яки сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя төзеп сөйли алу;<br>– укылган, тыңланган текстның төп эчтәлеген сөйләү;<br>– лексик тема буенча сөйләшү үткәрә алу;<br>– тәрҗемә итү күнекмәсе.</td></tr>
<tr><td>Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) СИУ</td></tr>
<tr><td>Эшне планлаштырырга өйрәнү</td><td>Балалар өчен нәшер ителгән китаплар, газета - журналларны, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йогерек һәм аңлап уку</td><td>Текстны укыганнан соң, төп фикерне башкаларыннан аера белү</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Эшнең дөреслеген тикшерү</td><td>Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку</td><td rowspan="2">0,5 – 1 минутлык текстны тыңлап аңлау һәм, төп эчтәлегенә төшенеп, укытучының сорауларына җавап бирә белү</td></tr>
<tr><td>Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү</td><td rowspan="2">Язма сөйләм:<br>– күчереп язу;<br>– план нигезендә изложение язу;<br>– аерым җөмләләрне, кечкенә текстларны үзгәрешсез күчереп язу (5-6 җөмлә);<br>– бирелгән тема буенча котлау язу;</td></tr>
<tr><td>Эш сыйфатына бәя бирә белү</td><td>Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү</td><td>Текстны тыңлау һәм бирелгән җөмләләр арасында эчтәлегенә туры килгәннәрен билгели алу</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |

# Уку 2 класс

| № | Дәреснең тибы | Дәреснең темасы | Сәгать саны | Үзләштерелергә, камилләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Контроль эш төрләре | Укучылар эшчәнлеге | Өй эше | Уздырылу вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | план | фак |
| **Балалар, әйдәгез мәктәпкә – 7 сәг.** | | | | | | | | | |
| 1 | Катнаш дәрес | БСҮ. И туган тел, и матур тел. Г.Тукай “Туган тел” | 1 | Г.Тукайның тормыш юлын кыскача истә калдыру. Сөйләм телен үстерү. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү. | | Портрет өстендә эш, иҗади уку, әңгәмә, җыр тыңлау, мультфильм, презентация карау | Г.Тукай “Туган тел” шигырьне ятларга | | |
| 2 | Әсәр өйрәнү дәресе | Г.Тукай, “Иртә”, “Ташбака илә куян” әсәрләре | 1 | Йөгек уку, әсәрләрнең эчтәлеген аңлап, башкаларга җиткерә алу, укучыларда тырышлык сыйфатлары тәрбияләү. | | Иҗади уку,эзләнү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү, рәсем ясау | 8 нче бит соаруларга җавап | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Әсәр өйрәнү дәресе | Р.Низамовадан, “Мәктәпкә барабыз” | 1 | “Мәктәпкә барабыз” әсәре белән танышу. Сөйләм телен үстерү.Белемгә омтылыш тәрбияләү | | Иҗади уку, чагыштыру, әңгәмә | “Мәктәпкә барабыз” СИУ | | |
| 4 | Катнаш дәрес | Ә.Бикчәнтәева, “Үрдәк беренчелекне алган”, “Язарга өйрәнгәндә” | 1 | Ә.Бикчәнтәеваның кыскача тормыш юлын истә калдыру. Сөйләм телен үстерү.Йөгерек уку күнекмәләрен үстерү.Тырышлык, тыйнаклык тәрбияләү. | | Портрет белән эшләү, иҗади уку, әңгәмә | 15 нче бит сорауларга җавап | | |
| 5 | Әсәр өйрәнү дәресе | А. Нигъмәтуллин, “Рөстәм төгәл исәпли”, И. Туктар. “Тырышкан – табар” әсәрләре | 1 | Әсәрләр белән танышу,эчтәлеген, әһәмиятен аңлап әйтә алу,тырыш булу. | | Уку, сүзлек эше, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 19 нчы бит мәкальләр не ятларга | | |
| 6 | Әсәр өйрәнү дәресе | З.Нури, “Көн дә мең дә бер сорау”, Х.Туфан. “Ял көнендә кырлар-болыннарда...” | 1 | Шигырь белән танышу. Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.Кызыксынучанлык, белемгә омтылу тәрбияләү | | Иҗади уку, эзләнү, әңгәмә | 21 нче бит “Көн дә мең дә бер сорау” сәнгатьле итеп укырга | | |
| 7 | Әсәр өйрәнү дәресе | Кереш контроль тест. (10 мин.) М.Гафури, “Мәктәп”, “Тырыш малай”, “Ана белән кыз” | 1 | Әсәрләр белән танышу,эчтәлеген, әһәмиятен аңлап әйтә алу,тырыш булу. | тест | Уку, сүзлек эше, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 11 нче бит, сорауларга җавап, “Ана белән кыз” СИУ | | |
| **Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта – 7 сәг.** | | | | | | | | | |
| 8 | Катнаш дәрес | Г.Тукай, “Көз”, “Кырлар буш кала” | 1 | Г.Тукай биографиясен сөйли алу. Шигырьне һәм хикәяне истә калдыру.Сөйләм телен үстерү.Табигатькә сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү | | Иҗади уку, чагыштыру, әңгәмә | 24 нче бит мәкальләрне ятларга | | |
| 9 | Катнаш дәрес | Муса Җәлил, “Көз җитте” | 1 | М. Җәлилнең тормыш юлын истә калдыру.Әйтергә теләгәнне әйтә алу. Эчтәлеген аңлау. Табигатькә сакчыл караш, мәхәббәт тәрбияләү | | Портрет белән эш, сүзлек, уку, эчтәлек сөйләү, сорауларга җавап. | 26 нчы бит “Көз җитте” шигырьне ятларга | | |
| 10 | Әсәр өйрәнү дәресе | Н.Сладков, “Көз” | 1 | Әсәр белән танышу. Йөгерек уку һәм рольләргә бүлеп уку күнекмәләрен үстерү. Хайваннарга һәм кошларга сакчыл караш тәрбияләү | | Иҗади уку,сөйләү алымы, әңгәмә | 24-25 нче бит СИУ, 25 нче бит сорауларга җавап | | |
| 11 | Әсәр өйрәнү дәресе | Б.Рәхмәт, “Кошлар киткәндә” | 1 | Шигырьне аңлау. Кошларга сакчыл караш, мәхәббәт тәрбияләү | | Сүзлек, СИУ, сорауларга җавап, уен. | 27 нче бит “Кошлар киткәндә” шигырьне ятларга | | |
| 12 | Әсәр өйрәнү дәресе | Г.Мөхәммәтшин, “Бәрәңге алганда” | 1 | Әсәр белән танышу. Йөгерек уку һәм рольләргә бүлеп уку күнекмәләрен үстерү. Хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү | | Иҗади уку,сөйләү алымы, план төзү, әңгәмә | 28-30 нчы бит “Бәрәңге алганда”, укырга, 29 бит рәсем буенча | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | эчтәлеген сөйләргә | | |
| 13 | Әсәр өйрәнү дәресе | Г.Галиев, “Айлар алышынганда”, М.Әхмәтҗанов, “Көз”. | 1 | Әсәрләрне аңлап кабул итү, йөгерек уку күнекмәләре булдыру,туган як табигатенә сакчыл караш, мәхәббәт тәрбияләү | | Иҗади уку,сөйләү алымы, кроссворд әңгәмә | 33 нче бит “Көз” шигырьне ятларга | | |
| 14 | БСҮ | Контроль эш. №1 . Г.Афзал, “Көз көне” | 1 | Укучыларның диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү. Аларны актив аралашуга тарту. Яшелчә исемнәрен белеп, уенда катнашу, телдән сөйләмнәрен, уй-фикерләүләрен үстерү. Әйтергә теләгәнне матур итеп җиткерә алу | Контроль эш | Уен, диалог, эзләнү, әңгәмә | 31нче бит “Көз көне” СИУ, сорауларга җавап | | |
| **Гаилә һәм туганнар – 7 сәг.** | | | | | | | | | |
| 15 | Катнаш дәрес | Г.Тукай, “Безнең гаилә”. З.Туфайлова, “Әни сүзе” | 1 | Г.Тукайның биографиясен истә калдыру. Сөйләм телен үстерү. Гаилә әгъзаларына ихтирам һәм мәхәббәт тәрбияләү. Әниләргә хөрмәт хисе, мәхәббәт тәрбияләү | | Иҗади уку, әңгәмә, рәсем ясау | 34 нче бит, рәсем буенча хикәя төзү | | |
| 16 | Катнаш дәрес | А.Алиш, “Әни ялга киткәч” | 1 | А.Алишның тормыш юлын истә калдыру. Йөгерек уку.Әниләргә хөрмәт хисе, мәхәббәт тәрбияләү | | Иҗади уку,портрет белән эшләү, әңгәмә, презентация | 35-36 нчы бит“Әни ялга киткәч” укырга, 37 нче бит сорауларга җавап | | |
| 17 | Катнаш дәрес | Р. Корбанов, “Бүре” диеп язган идем...” Ә.Бикчәнтәева, “Әтием белән бергә” | 1 | Әтиләргә хөрмәт хисе, мәхәббәт тәрбияләү. Ә.Бикчәнтәеваның кем икәнен әйтә алу. Әсәрләрнең эчтәлеген аңлап, башкаларга җиткерә алу, сорауларга аңлап җавап бирү | | Сүзлек эше, СИУ, сорауларга җавап | 38 нче бит “Әтием белән бергә” СИУ | | |
| 18 | Әсәр өйрәнү дәресе | Р.Вәлиева, “Дәү әни”, Х.Халиков, “Дәү әти” | 1 | Хикәя һәм шигырь белән танышу. Йөгерек һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен ныгыту. Әби-бабайга хөрмәт хисе, мәхәббәт тәрбияләү | | Иҗади уку, әңгәмә, сорауларга җавап | 39-40 нчы бит “Дәү әнием” СИУ, 41 нче бит сорауларга җавап | | |
| **2 нче чирек** | | | | | | | | | |
| 19 | Әсәр өйрәнү дәресе | Ә.Фәйзи “Чәй эчәбез бал белән”, Г. Мөхәммәтшин “Әйдәгез, танышабыз: мин гап-гади Инсаф” | 1 | Әсәрләрнең эчтәлеген аңлап, башкаларга җиткерә алу, сорауларга аңлап җавап бирү. Татар халык исемнәренә кызыксыну, алар белән горурлану хисе. | | Иҗади уку, сөйләү, эзләнү, әңгәмә | 44-б. СИУ 46-б. сорауларга җавап | | |
| 20 | Катнаш дәрес | Р.Миңнуллин “Әни” | 1 | Р.Миңнуллинның биографиясен истә калдыру. Шигырьне аңлау, әһәмиятен әйтә алу, сиу. Әниләргә хөрмәт. | | Иҗади уку, сөйләү, эзләнү, портрет белән эш, | 46-б “Әни” шигырен ятларга | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | әңгәмә, презентация | | | |
| 21 | БСҮ | Әниләр бәйрәме. *З. Мансур* *“Әниләр көнендә”* | 1 | Укучыларның диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү. Аларны актив аралашуга тарту. Әсәрне аңлау, әниләр көненең кайчан үткәрелүен белү, аларга ярдәм, мәхәббәт. | | Сөйләү, рәсем өстендә эш, шигырьләр, җырлар тыңлау | “Кадерле әнием” хикәя | | |
| **Ак чәчәкләр ява – 8 сәг.** | | | | | | | | | |
| 22 | Катнаш дәрес | Г.Тукай “Җир йокысы”, “Кыш”, “*Кояш*” | 1 | Г.Тукайның тормыш юлын һәм танышкан әсәрләрен әйтә алу. “Җир йокысы” һәм “Кыш” шигырьләре белән танышу. Сөйләм телен үстерү. Табигатькә сак караш һәм ярату. | | Иҗади уку, сөйләү, эзләнү, портрет белән эш, әңгәмә | 49-б. “Җир йокысы” шигырьне ятларга | | |
| 23 | Катнаш дәрес | З.Нури “Кар яуган”, “Карга” Ә.Бикчәнтәева “Карлар ява” | 1 | Яңа әсәрләр белән танышу. Яңа сүзләрне истә калдыру. Сөйләм телен үстерү. Хайваннарга, табигатькә сак караш, ярату | | Әңгәмә, сүзлек эше, иҗади уку, эзләнү | 57-б. СИУ, 52-б. “Карлар ява” рәсем ясарга | | |
| 24 | Әсәр өйрәнү дәресе | В.Монасыйпов “Кем белән кем” | 1 | Яңа сүзләрне истә калдыру. Әсәрләрне аңлап, төп фикерен әйтә алу. Матурлыкны күрә белергә өйрәнү. | | Әңгәмә, сүзлек эше, иҗади уку, эзләнү | 53, 54-б. сүзлек | | |
| 25 | Әсәр өйрәнү дәресе | Н. Дәүли “Календарьның соңгы бите” И.Туктар “Җем-җем!..Чвик!..” | 1 | Әсәр белән танышу. Яңа сүзләрне истә калдыру. Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен булдыру. Кошларга сак караш, ярату. | | Иҗади уку, әңгәмә, сүзлек эше | 55-б. “Календарьның соңгы бите” эчтәлеген сөйләргә, 59-б. сүзлек | | |
| 26 | Әсәр өйрәнү дәресе | С. Урайский “Чыршы” Г. Зәйнашева “Тукран белән сөйләшү” | 1 | Яңа әсәр белән танышу. Яңа сүзләрне истә калдыру. Сөйләм телен үстерү. | | Әңгәмә, сүзлек эше, иҗади уку, эзләнү, уен | 60-б. сүзлек, 61-б. табышмакларның җавабын әйт | | |
| 27 | Әсәр өйрәнү дәресе | Д. Аппакова “Тагын урамга” Р.Корбанов “Урак өсте” | 1 | Яңа әсәрләр белән танышу. Яңа сүзләрне истә калдыру. Сөйләм телен үстерү. | | Әңгәмә, сүзлек эше, иҗади уку, эзләнү | 62-б. “Тагы урамга” эчтәлеген сөйләргә | | |
| 28 | Әсәр өйрәнү дәресе | М. Әхмәтҗанов. “Яңгырлы яңа ел”, “Яңа ел”, “Безнең дәрес” | 1 | Яңа сүзләрне истә калдыру. Әсәрләрне аңлап, төп фикерен әйтә алу. Матурлыкны күрә белергә өйрәнү. | | Әңгәмә, сүзлек эше, иҗади уку, эзләнү | Рәсем ясарга | | |
| 29 | Катнаш дәрес | Контроль эш . БСҮ. Яшел чыршы янында | 1 | Өйрәнгәннәрне контроль эштә күрсәтә алу. Яңа ел бәйрәме турында сөйләү.Үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү. | Контроль эш | Контроль эш биремнәрен үтәү. Әңгәмә, презентация буенча эш | 1 тизәйткеч ятларга | | |
| **Үзе яхшының эше дә яхшы – 5 сәг.** | | | | | | | | | |
| 30 | Әсәр өйрәнү | И.Туктар “Рәхмәт һәркем өчен рәхәт”, | 1 | Әсәрләр белән танышу. Сөйләм телен үстерү. Рольләргә бүлеп уку күнекмәләрен ныгыту. | | Сүзлек эше, иҗади уку, әңгәмә, | 1 әсәрнең эчтәлеген | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дәресе | *“Ялкау өчен ботка суынган”,*<br>*“Тырышкан табар”* | | Өлкән кешеләргә ярдәм итәргә омтылу хисе тәрбияләү. | | эзләнү, план төзү, рәсем өстендә эш | белергә (теләк буенча) | | |
| 31 | Әсәр өйрәнү дәресе | Р.Корбанов “Уйнап”,<br>Р.Вәлиева<br>“Кыңгырау чәчәк” | 1 | Әсәр белән танышу. Йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Якыннарыңа, туганнарыңа хөрмәт хисләре. | | Әңгәмә, сүзлек эше, иҗади уку, эчтәлек сөйләү | 69-б. сорауларга җавап | | |
| 32 | Катнаш дәрес | И. Туктар<br>“Борын”<br>Т.Миңнуллин<br>“Үзем белән үзем” | 1 | Т.Миңнуллинның тормыш юлы турында әйтә алу. Әкият белән танышу. Рольләргә бүлеп уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Укучыларда эшчәнлек һәм төгәллек сыйфатларын тәрбияләү. | | Портрет белән эш, иҗади уку, әңгәмә,сорауларга җавап бирү | 72-б. башваткычл арны чиш, 75-б. “Үзем белән үзем” СИУ | | |
| **3 нче чирек** | | | | | | | | | |
| 33 | Әсәр өйрәнү дәресе | М. Хәсәнов<br>“Оялчан Хаҗи” | 1 | Әсәр белән танышу. Рольләргә бүлеп һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Балаларны тыйнак һәм әдәпле булуга өндәү. | | Әңгәмә, иҗади уку, эчтәлек сөйләү | 78-б. “Оялчан Хаҗи” әсәрнең әһәмиятен әйтергә | | |
| 34 | Катнаш дәрес | *Ф.Яруллин*<br>*“Әйбәт тә минем әби”* | 1 | Ф. Яруллинның тормыш юлын истә калдыру. Әсәр белән танышу. Йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Үз әниең белән горурлану хисләре. | | Портрет белән эш, сүзлек, әсәрне уку, әңгәмә, сорауларга җавап | Әсәрнең эчтәлеген белергә | | |
| **Туган җир, туган ил – 7 сәг.** | | | | | | | | | |
| 35 | Катнаш дәрес | Р.Вәлиева<br>“Иң матур җир”,<br>Т. Миңнуллин<br>“Ватан” | 1 | Сәнгатьле уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Туган илгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисе тәрбияләү. | | Сүзлек, иҗади уку, әңгәмә, җырлау | 81-б. “Иң матур җир” СИУ | | |
| 36 | Катнаш дәрес | З.Туфайлова<br>“Туган ил”,<br>Безнең туган илебез – Татарстан Республикасы | 1 | Шигырь белән танышу.Сәнгатьле уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Туган илгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисе тәрбияләү. | | Иҗади уку, әңгәмә, җырлау | 83-б. “Туган ил” шигырьне ятларга | | |
| 37 | Әсәр өйрәнү дәресе | Р. Фәйзуллин<br>“Шагыйрь булсаң”<br>Кәрим Әмири<br>“Безнең авыл” | 1 | Яңа сүзләрне истә калдыру. Әсәрләрне аңлап, төп фикерен әйтә алу. Үз туган җиреңбелән горурлану. | | Сүзлек эше, әңгәмә, әсәр уку, группалап эш, сорау-җавап | Әсәргә туры килгән мәкальләр (4) | | |
| 38 | Әсәр өйрәнү дәресе | “Салават күпере” журналыннан<br>“Ике мең ел элек”<br>*Г.Дәүләтшин*<br>*“Нәрсә соң ул Туган ил?”* | 1 | Әсәр белән танышу.Сәнгатьле уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Туган илгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисе тәрбияләү | | Иҗади уку, әңгәмә, җырлау | Сорауларга җавап | | |
| 39 | Әсәр өйрәнү дәресе | *Мидхәт Миншин*<br>*“Серле күл”* | 1 | Әсәр белән танышу.Сәнгатьле уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Матурлыкны күрә белү. | | Сүзлек эше, әңгәмә, әсәр уку, сорау-җавап, | Эчтәлеген белергә | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | рәсем ясау | | | |
| 40, 41 | БСҮ | Без Татарстанда яшибез. Минем туган җирем. | 2 | Укучыларның диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү. Аларны актив аралашуга тарту .Үз туган җиреӊ турында сөйли алу. Үз телеӊ, илеӊ, халкыӊ белән горурлану. | | Презентация, әӊгәмә, җыр тыӊлау | Хикәя язарга | | |
| **Яз – 5 сәг. +1 сәг. контроль дәрес** | | | | | | | | | |
| 42 | Әсәр өйрәнү дәресе | Н.Измайлова “Менә нинди икән яз!” Г. Хәсәнов “Яз” | 1 | Шигырь белән танышу.Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Яз ел фасылына карата соклану, ярату хисе тәрбияләү. | | Иҗади уку, әӊгәмә, биремнәр үтәү, җырлау | 90-б. “Менә нинди икән яз!” СИУ | | |
| 43 | Катнаш дәрес | З. Мансур “Әниләр көнендә” Д.Аппакова “Март башы*”, “Тагын урамга”* | 1 | Әсәр белән танышу.Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту.Д.Аппакованыӊ тормыш юлын, әсәрләрен белү. Сөйләм телен үстерү. Яз ел фасылына карата соклану, ярату хисе тәрбияләү. | | Иҗади уку, әӊгәмә, биремнәр үтәү | 92-б. “Әниләр көнендә” СИУ 94-б. табышмакларга җавап | | |
| 44 | Әсәр өйрәнү дәресе | Г.Лотфи “Сыерчык”, “Яз җыры” | 1 | Әсәрләр белән танышу.Сәнгатьле уку. Сөйләм телен үстерү. Кошларны ярату, саклау. | | Иҗади уку, әӊгәмә, биремнәр үтәү, презентация, рәсем ясау | 95-б. “Сыерчык” ятларга | 21.02 | |
| 45 | Әсәр өйрәнү дәресе | Э. Касыймов “Боз кузгалды” М. Җәлил “Күке” | 1 | Әсәр белән танышу.Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Табигатькә соклану, ярату хисе. | | Иҗади уку, әӊгәмә, биремнәр үтәү | 97-б. сүзлек, эчтәлеген сөйләргә | 27.02 | |
| 46 | Катнаш дәрес | Лев Толстой, “Көймә”. Җ. Тәрҗеманов, “Кояш чыкты” | 1 | Әсәр белән танышу.Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Табигатькә соклану, ярату хисе. 2 әсәрнеӊ уртак һәм аермалы якларын табу. | | Сүзлек эше, уку, биремнәр үтәү, чагыштыру. | Контроль эшкә әзерләнергә | | |
| 47 | Контроль дәрес | Контроль эш.”Яз” | 1 | Контроль эш биремнәрен аӊлап эшли алу. | Контроль эш | Контроль эш биремнәрен үтәү | Сүзлек кабатларга | | |
| **Язучылар иҗат иткән әкиятләр – 3 сәг.** | | | | | | | | | |
| 48 | Әсәр өйрәнү дәресе | Р.Батулла. “Куян баласы Нуяк” ф | 1 | Әкият танышу.Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Хәйләкәр булмаска,ачык йөзле, кунакчыл булырга өндәү. | | Иҗади уку, әӊгәмә, сөйләү | Сөйләргә өйрәнергә | | |
| 49 | Әсәр өйрәнү дәресе | Ф.Яруллин. “Урман әкияте” | 1 | Әкият белән танышу. Эчтәлеген аӊлап, эчтәлеген башкаларга җиткерә алу. Әкиятләргә кызыксыну. | | Сүзлек эше, уку, сорау – җавап, иллюстрацияләр ясау | Рәсем ясарга | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 50 | БСҮ | Сөйләшү өчен тема: “Күркәм әдәпле сүзләр” | 1 | Укучыларның диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү. Аларны актив аралашуга тарту. Әдәпле сүзләрне көндәлек сөйләмгә кертү. Балаларны тыйнак, тәрбияле һәм әдәпле булуга өндәү. | | Әңгәмә, эзләнү, иҗади эш | Хикәя төзеп язарга | | |
| **Әкиятләр – 6сәг**. | | | | | | | | | |
| 51 | Әсәр өйрәнү дәресе | “Өч кыз” (татар халык әкияте) Хәйләгә каршы хәйлә (татар халык әкияте) | 1 | Әкият белән танышу. Рольләргә бүлеп һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү. Әниләргә хөрмәт хисе, ярдәм итәргә омтылу хисе тәрбияләү. | | Иҗади уку, әңгәмә, сүзлек эше, сөйләү, план төзү | 103-б. укырга, рәсем ясарга | | |
| 52 | Әсәр өйрәнү дәресе | Кәҗә белән бүре (татар халык әкияте) | 1 | Әкият белән танышу. Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту.Сөйләм телен үстерү. Әкиятләргә кызыксыну, ярату тәрбияләү | | Иҗади уку, әңгәмә, эзләнү, сөйләү | 107-б. эчтәлеген сөйләргә | | |
| | | | | | | | | | |

3 класс татар теле

Аңлатма язуы

*Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:*

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының”Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты”(вакытлыча) Казан,2008
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” (татар балалары өчен). 1-11нче сыйныфлар Казан”Мәгариф” нәшрияты 2010
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Азнакай шәһәре 4 нче лицее” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең төп гомуми белем өчен төп белем программасы
4. Татар теле: рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен)/ Ф.Ф.Харисов, Ф.М. Хисамова, Ч.М.Харисова. - Тулыл.2 нче басма. - Казан: Мәгариф, 2009. – 150б.; рәс. б-н.

*Рус мәктәбенең башлангыч сыйныфларында укучы татар балалары өчен төзелгән татар теле программасы түбәндәге максат һәм бурычларны үз эченә ала:*

- Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнүгә теләк уяту, үз милләтеңә, телеңә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру;

- Балаларда татар теле буенча мәгълүматлылык булдыру;

-Фонетика, лексика, сүз ясалышы, грамматика, стилистикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;

-Телебезнең орфоэпиясе, лексикасы, грамматикасы, пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау.

-Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълүматлар булдыру. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча әйткәнне аңларга, аңлаганны тыңлаучыга - җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.

- Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

- Укучыларда татар этнокультурасы буенча мәгълүматлылыкны үстерү.

*3 нче сыйныфта татар теленнән белем бирү максатлары*

Төрле типтагы сүзлекләр һәм аларның төзелү принциплары белән таныштыру.
Тамыр, кушымча һәм аларның төрләре белән таныштыру.
Сүз төркемнәреннән сан, зат алмашлыклары, фигыль заманнары белән танышу.
Җөмләнең баш кисәкләре, аергыч турында мәгълүмат бирү.
Рәсемнәр яки укылган өзекнең эчтәлеге буенча кечкенә изложение, сочинениеләр язганда, укучылар татарча җөмләләрне дөрес төзү күнекмәләре булдыру.

*Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:*

-татар алфавитын яттан белү;

-калын һәм нечкә сузыкларны аеру;

-яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру;

-сүз басымын дөрес кую;

-исем,фигыль һәм сыйфатларны җөмлә эченнән таба белү;

-җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү.

*3 нче сыйныф ахырына укучылар татар теленнән түбәндәге белем, осталык һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш:*

*1. Грамматик минимум.*

- Сүзләргә фонетик анализ ясау( сүзне иҗекләргә бүлеп, басымны билгеләү, авазлар һәм хәрефләр санын әйтү, калын-нечкә сузыклар, яңгырау-саңгырау тартыкларны күрсәтү).
- Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсен, күп мәгънәле булуын аеру.
- Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә куллану.
- Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.
  - Сүз төзелешен тикшерү күнегүләрен үтәү.Укытучы биргән сүзләрнең тамырын, кушымчаларын табу.
  - Кушма һәм парлы сүзләрнең ясалышын аңлату, язылышын күзәтү. Алар белән җөмләләр төзү, сүзлек диктанты һәм аңлатмалы диктантлар язу.
  - Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрне аеру, берлек һәм күплек сандагы исемнәрне килеш блән төрләндерү.
  - Сыйфатларның сыйфатланмышка, саннарның саналмышка иярү үзенчәлеген ( янәшә тору) аңлау.
  - Саннар янында килгән саналмышның татар телендә берлек санда кулланылуын истә калдыру.
  - Зат һәм сорау алмашлыкларын башка сүз төркемнәреннән аеру, аларны диалогик һәм монологик сөйләмдә куллану.
  - Фигыльләрнең заманнарын билгеләү, хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнешен язма һәм телдән сөйләмдә дөрес куллану.
  - Өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү.
  - Җөмләнең баш кисәкләрен таба белү.
  - Иярчен кисәкләрдән аергычны билгеләү, аның аерылмышка иярү үзенчәлеген аңлау.

*2. Язу.*

- Бирелгән темага сочинение язу.
- Орфографик күнегүләрдән соң тыныш билгеләре булган диктантлар язу.
- План нигезендә изложение язу.
- Татар этнокультурасына караган сүзләр кертеп, җөмләләр язу.
- Үзең, гаилә, мәктәп турында кечкенә хикәяләр яки котлау кәгазьләре язу.

2011/2012 нче уку елына анализ.

2011/2012 нче уку елында 2 нче А сыйныфының татар төркемендә татар теле дәресләре “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программасы”на нигезләнеп, 2нче сыйныф өчен Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, А.К. Җәләлиева тарафыннан эшләнгән дәреслек буенча 102 сәгать укытылган.Программа тулысынча үтәлгән. Укучылар аерым сүзләр һәм сүзтезмәләрне, җөмләләрне дөрес итеп укый һәм язарга өйрәнгәннәр. Бирелгән иҗекләрдән сүзләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзеп әйтә беләләр. Тәкъдим ителгән җөмләләрне дөрес итеп күчереп язалар.Баш хәреф белән языла торган сүзләрне беләләр.Кайбер укучылар сүзләрне юлдан-юлга күчергәндә хата ясыйлар.Матур язу өстендә дә эшләргә кирәк. Өлгереш-100%, сыйфат- 70 % тәшкил иткән..Шушы нәтиҗәләрдән чыгып, 3 нче А сыйныфы өчен түбәндәге эш программасы төзелде.

*Эш программасының эчтәлеге.*

| № | Бүлекләр | Барлыгы | Теоретик материал | Кабатлау | Бәйләнешле сөйләм үстерү |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау | 17 | - | 11 | 6 |
| 2 | Сүз. | 10 | 9 | - | 1 |
| 3 | Сүз төзелеше һәм ясалышы | 12 | 10 | 1 | 1 |
| 4 | Морфология. | 41 | 25 | 4 | 12 |
| 5 | Синтаксис. | 18 | 14 | 2 | 2 |
| 6 | Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 4 | - | 2 | 2 |
| | Барлыгы | 102 | 58 | 20 | 24 |

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының татар теленнәнбелем һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары

Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү

| Сүзлек диктанты | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
|---|---|---|---|
| 4 | 4 | 1 | 1 |

Диалогик сөйләмне бәяләү:

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге яганнан эзлекле һәм диалогик сөйләм (репликалар саны 4/4) төзегәндә, “5”ле куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтәлешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, “4”ле куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә, “3”ле куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда, “2” ле куела.

Монологик сөйләмне бәяләү:

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле булган монологик сөйләм өчен “5”ле куела. Монологик сөйләмдә фразалар саны 6.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән  тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләренең әйтелешендә, грамматик фромаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хатасы булган монологик сөйләм өчен “4”ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4-6 хатасы булган монологик сөйләм өчен “3”ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог төзи алмаганда, “2”ле куела.

Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү.

Телдән сөйләү белән бергә, башлангыч сыйныфларда язу күнекмәләре дә формалаштырыла. Моның өчен түбәндәге язма эшләр башкарыла:

1. татарча сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, текстларны күчереп яки ишетеп язу;
2. сорауларга җавап язу;
3. сүзлек яки контроль диктантлар язу;
4. изложение язу;
5. сочинение язу.

Матур язуга караган кимчелекләрне төзәтү дә язу күнегүләренә керә.

Матур язуның күләме: 3-4 нче сыйныфларда 3 юлдан артмаска тиеш.

Бу эш һәр дәрестә алып барыла: язма эшләр тикшерелә, укучылар белән бергә хаталарны төзәтү өстендә эш үткәрелә.

Күчереп язу өчен сүз һәм җөмләләр күләме.

| Сыйныф | Эш төрләре | |
|---|---|---|
| | Сүзләр | Җөмләләр |
| 3 | 13-20 | 6-8 |

Күчереп язуны бәяләү.

Пөхтә итеп язылган, орфографик хаталары булмаган, ләкин 1-2 җирдә хәрефләрнең урыны алышынган булса, “5”ле куела.

Эш бик үк чиста итеп башкарылмаса, 1-2 хата җибәрелсә, хәрефләрнең урыны алышынса, “4”ле куела.

Язуда 3-5 хата җибәрелсә яки хәрефләрнең урыны алышынса, текст пөхтә итеп язылмаса, төзәтүләр булса, “3”ле куела.

Хаталар саны 5 тән артса, төзәтүләр күп булса, “2”ле куела.

Диктант, изложение, сочинениеләрдәге сүзләр саны түбәндәгечә була.

| Сыйныфлар | Эш төрләре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Сүзлек диктанты | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
| 3 | 10-12 | 25-30 | | 15-20 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 20-25 | |

Диктант итеп аерым сүзләр яки текст яздырыла. Аны уздыру вакытын укытучы үзе билгели. Аерым сүзләрне дөрес язу күнекмәләрен тикшерү өчен, сүзлек диктантлары үткәрелә.

1-2 нче сыйныфларда орфографик хаталар гына искә алына. 3 нче сыйныфта аларга тыныш билгеләренә караганнары да өстәлә.

Хатасыз яки тупас булмаган 1 хата җибәрелгән, дөрес каллиграфия белән матур итеп язылган эшкә "5"ле куела.

3 тән артык хата булмаган һәм пөхтә итеп язылган; хатасыз, ләкин төзәтүләр белән бик үк пөхтә язылмаган эшкә "4"ле куела.

5 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә "3"ле куела.

Изложение һәм сочинение яздыру укучылырның язма сөйләм, грамматик һәм орфографик күнекмәләрен тикшерергә ярдәм итә. Бу эш алдан әзерлек алып баргач уздырыла.

Язма эшләрнең бу төрләренә караган төп таләпләр: эчтәлекне дөрес һәм эзлекле итеп ачып бирү, хатасыз язу. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен бер билге куела.

Изложение һәм сочинениеләрне бәяләү.

Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә, хаталар булмаса яки 1 орфографик (1 җөмлә төзелешендә) хата җибәрелсә, "5"ле куела.

Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса яки пөхтә башкарылып, эзлеклелек булып та, сүз сайлауда һәм җөмлә төзүдә 2-3 хата булса, "4"ле куела.

Текстның яки рәсемнең төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса; 4-6 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда һәм җөмләләр төзегәндә, 4-5 төгәлсезлек китсә, "3"ле куела.

Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылмаса, 7-10 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда һәм җөмләләр төзегәндә, 6-7 хата китсә, "2"ле куела.

Сүзлек диктантларын бәяләү.

1. Хаталары булмаган эшкә "5"ле куела.
2. 1 хата, 1 төзәтелгән хата булса, "4"ле куела.

3. 2 хата, 1 төзәтелгән хата булса, “3”ле куела.

4. 3-5 хата булса, “2”ле куела.

5. 6 хатадан артып китсә, “1”ле куела.

*Укыту – методик комплекты*

1.Рус мәктәпләрендә ана теле укыту. Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова, Казан. “Мәгариф” , 2008.

2.Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр. 3-4нче сыйныф. Я.Х. Абдрәхимова, Казан, “Мәгариф”, 2008.

3.Татар теленнән диктантлар. 1-4 нче сыйныф, Казан, “Мәгариф” нәшр.,2006.

4. Кызыклы грамматика. С. Г. Вәгыйзов, Казан: “Мәгариф”, 2002.

5.Татар теленнән иҗади сочинениеләр һәм изложениеләр язарга өйрәтү. 1-4 нче сыйныф. М.Җ.Ахиярова, И.Х. Мияссарова, Ф.Ш. Гарифуллина, Казан: “Мәгариф”, 2009.

| № | Тема | сәг сан | Уку-укыту эшчәнлегенең төрләре | Материалны үзләштерү буенча планлаштырылган нәтиҗәләр | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | план | факт |
| 2нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау (17 сәг) | | | | | | |
| 1 | БСҮ. №1 Туган тел турында әңгәмә | 1 | Тел турында мәкальләрне искә төшерү,рәсем буенча сөйләшү | Хикәя төзү | | |
| 2 | Авазлар һәм хәрефләр. | 1 | Сүздә ничә аваз, хәреф барлыгын билгеләү буенча күнегүләр эшләү. | Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Транскрипция. | | |
| 3 | Сузык һәм тартык авазлар. | 1 | Уку, тәрҗемә итү, сүзләр язу. | Сузык һәм тартык авазларны аеру. | | |
| 4 | Калынлык һәм нечкәлек билгеләре. | 1 | Табышмаклар уку сүзләр язу, язылышын аңлату. | Ъ һәм ь хәрефләре булган сүзләрне дөрес язу һәм уку. | | |
| 5 | Сүзләрне иҗекләргә аеру. | 1 | Сүзләрне иҗекләргә аерып язу, басымын кую. | Сүздәге иҗек санын билгели белү. Сүз басымын дөрес билгели белү. | | |
| 6 | БСҮ №2 Җәйге ял.Сүз басымы. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Хикәя төзү | | |
| 7 | Сүзләргә фонетик анализ ясау. | 1 | Сүздә ничә аваз, хәреф барлыгын билгеләү, басымын кую. | Сузык һәм тартык авазларны аеру. Фонетик анализ ясарга өйрәнү. | | |
| 8 | Фонетик анализ | | Авазлар һәм хәрефләр санын тикшерү | Фонетик анализ ясауны камилләштерү | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күнекмәләре | | | | | |
| 9 | Кереш диктант. | 1 | Грамоталы язу күнекмәсен тикшерү. | | | |
| 10 | Хаталар өстендә эш.Монологик сөйләм үстерү №3 Без мәктәпкә барабыз | 1 | Хаталарны анализлау | Сүзләрнең язылышын истә калдыру | | |
| 11 | Сүз төркемнәре.Исем. | 1 | Уку, исемнәрне табу, сораулар кую. | Исемнең мәгънәсен аңлап, җөмлә эченнән табып әйтү. Исемнең берлек һәм күплек сан формаларын аеру. | | |
| 12 | БСҮ №4 Физкультура дәресендә.Фигыль. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү.Күнегүләр эшләү. | Фигыльнең мәгънәсен аңлап, җөмлә эченнән таба белү. | | |
| 13 | Сыйфат. | 1 | Предметларның билгеләрен әйтү, татарчага тәрҗемә итү. | Сыйфатның мәгънәсен аңлап, җөмлә эченнән таба белү. | | |
| 14 | Җөмләнең баш кисәкләре. | 1 | Җөмләләрдән ия белән хәбәрне табу, сүзләрдән җөмләләр төзү. | Җөмләнең баш кисәкләрен таба белү. | | |
| 15 | БСҮ №5 Көзге табигать | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Хикәя төзү | | |
| 16 | БСҮ №6 Көндәлек режимы | 1 | Җөмләләр , тема буенча диалог төзү. | Рәсем буенча хикәя төзү. | | |
| 17 | Мөстәкыйль эш №1 Җөмлә кисәкләре. | 1 | Мөстәкыйль эш эшләү | Җөмлә кисәкләре турында мөстәкыйль фикер йөртү | | |
| | | | Сүз | | | |
| 18 | Сүз турында гомуми мәгълүмат | 1 | Төрле биремнәр эшләү. | Сүз турында белгәннәрне искә төшерү. | | |
| 19 | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. | 1 | Уку, сүзләрнең мәгънәләрен аңлату. | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аера белү. | | |
| 20 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр | 1 | Уку, җөмләләр төзү. | Бер мәгънәле сүзләрне күп мәгънәле сүзләрдән аера белү. | | |
| 21 | Синонимнар. Омонимнар. | 1 | Сүзләрне уку, мәгънәләрен аңлату, синонимнарын табу, мәгънәләрен аңлату ребусны чишү. | Синоним, омоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә дөрес куллану | | |
| 22 | Антонимнар. | 1 | Уку, капма-каршы мәгънәле сүзләрне табу. | Антонимнарны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә дөрес куллану. | | |
| 23 | Синоним, омоним, антонимнарны ныгыту.Сүзлек | 1 | Сүзләрне уку, мәгъ нәләрен аңлату, синонимнарын табу, ребусны чишү. | Синоним, омоним, антонимнарны тексттан табу, сөйләмдә куллана белү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | диктанты. | | | | | |
| 24 | Сүзлекләр турында мәгълүмат. | 1 | Күнегүләр эшләү. | Сүзлекләр белән эшли белү. | | |
| 25 | Контроль диктант №1 | 1 | Ишетеп язу, биремнәр эшләү. | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | | |
| 26 | Хат.өст. эш. Тамыр | 1 | Уку, сүзләрнең тамырларын табу. | Сүзләрнең тамырын таба белү. | | |
| 27 | БСҮ №7 Кышкы матурлык. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Кышкы матурлык темасына хикәя төзү | | |
| Сүз төзелеше һәм ясалышы (12 сәг.) | | | | | | |
| 28 | Кушымча. | 1 | Сүзләрнең кушымчаларын табу. | Кушымчаларны тамырдан аеру. | | |
| 29 | Тамырдаш сүзләр. | 1 | Сүзләрнең тамырларын билгеләү. | Тамырдаш сүзнең төрле ясагыч кушымчалар ярдәмендә бер үк тамырдан ясалуын белү. | | |
| 30 | БСҮ №8 Туган як чишмәләре. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Туган як чишмәләре темасына хикәя төзү | | |
| 31 | Сүз ясагыч кушымчалар. | 1 | Җөмләләр төзү, биремнәр эшләү | Сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау. | | |
| 32 | Бер тамырга берничә төрле кушымча ялгану. | 1 | Уку, тамыр һәм ясалма сүзләрне табу. | Татар телендә тамырга башта ясагыч кушымча, аннары мөнәсәбәт белде-рүче кушымчаларның ялгануын белү. | | |
| 33 | Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. | 1 | Сүзләрне тамыр һәм кушымчага аеру. | Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны аера белү. | | |
| 34 | Татар һәм рус телләрендә кушымчалар ялгану үзенчәлекләре. | 1 | Уку,сүзләрнең кушымчаларын күрсәтү. | Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчалар ялгануның үзенчәлекләрен белү. | | |
| 35 | Тамыр һәм ясалма сүзләр. | 1 | Тәрҗемә итү, язу, кушымчаларын күрсәтү. | Тамыр һәм ясалма сүзләрнең ясалышын белү. | | |
| 36 | Кушма сүзләр | 1 | Кушма сүзләр төзү. Парлы сүзләр төзү. | Кушма сүзләрнең ясалышын һәм язылышын белү. | | |
| 37 | Парлы сүзләр | 1 | Парлы сүзләр төзү. | Парлы сүзләрнең ясалышын һәм язылышын белү. | | |
| 38 | Сүз төзелеше бүлеген кабатлау | 1 | Төрле биремнәр эшләү. | Лексик материалның үзләштерүне системалаштыру. | | |
| 39 | Иҗади диктант . Сүз төзелеше | 1 | Тамыр сүзләргә кушымчалар өстәп, текстны тутырып язу | Лексик материалның үзләштерүне системалаштыру. | | |
| 40 | Морфология.Исем. | 1 | Уку, исемнәрне табу Морфология (41 сәг) | Хаталарны төзәтү. Исем турында өйрәнгәннәрне искә төшерү, сораулар | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | буенча предметны бел-дергән сүзләрне таба белү | | |
| 41 | БСҮ №9 Безнең сыйныф бүлмәсе. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Безнең сыйныф бүлмәсе темасына хикәя төзү | | |
| 42 | Исемнәрнең берлек һәм күплек формалары. | 1 | Сораулар кую, күплек санда язу. | Сораулар буенча предметны белдергән сүзләрне таба белү,берлек һәм күплек сандагы исемнәрне үзләштерү. | | |
| 43 | БСҮ №10 Кышкы көндә | 1 | “Кышкы көндә” темасы буенча сөйләшү. | Хикәя төзү | | |
| 44- | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 1 | Диалог төзү, ялгызлык исемнәрне табу, | Ялгызлык исемнәрен дөрес яза белү. | | |
| 46 | БСҮ №11 Сочинение №1 Туган ягыма кыш килде | 1 | План төзү,телдән һәм язма эш. | Сочинение яза белү | | |
| 47 | БСҮ №12 Диалогик сөйләм үстерү. | 1 | Диалог төзү | Диалогик сөйләм үстерү | | |
| 48 | Контроль диктант №2 административ | 1 | Ишетеп язу, биремнәр эшләү. | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | | |
| 49 | Хаталар өстендә эш. | 1 | Хаталы сүзләр белән сүзтезмәләр ,җөмләләр төзү. | Сүзләрнең язылышын истә калдыру. | | |
| 50 | Татар телендә килешләр. | 1 | Сүзләрнең кушымчаларын табу, язу Исемнәрне килеш белән төрләндерү. | Килешләрне һәм сорауларын истә калдыру Исемнәрнең берлектә һәм күплектә килеш белән төрләнешен белү. | | |
| 51 | Баш килеш. | 1 | Җөмләләр төзү, баш килешендәге сүзләрне табу. | Баш килештәге исемнәрне сөйләмдә куллану. | | |
| 52 | Иялек килеше. | 1 | Җөмләләр төзү, иялек килешендәге сүзләрне табу. | Иялек килешендә килгән исемнәргә -ның, -нең кушымчалары ялгануын үзләштерү. | | |
| 53 | Юнәлеш килеше. | 1 | Җөмләләр язу, сүзләрне килеш белән төрләндерү. | Юнәлеш килешен истә калдыру. Исемнәрнең юнәлеш килешендә төрләнешен белү. | | |
| 54 | Төшем килеше. | 1 | Җөмләләр язу, сүзләрне килеш белән төрләндерү. | Төшем килешен истә калдыру.Исемнәрнең төшем килешендә төрләнешен белү. | | |
| 55 | Чыгыш килеше. | 1 | Күп нокталар урынына тиешле кушымчалар куеп язу. | Исемнәрнең чыгыш килешендә төрләнешен белү. | | |
| 56 | БСҮ №13 Татарстан елгалары | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Татарстан елгалары темасына хикәя төзү | | |
| 57 | Урын-вакыт килеше. | 1 | Җөмләләр язу, сүзләрне килеш белән төрләндерү. | Исемнәрнең урын- вакыт килешендә төрләнешен белү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 58 | БСҮ №14 Кышкы матур көндә. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Кышкы матур көндә темасына хикәя төзү | | |
| 59 | Исемнәрне гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Сорауларга җавап бирү, биремнәр эшләү | Исемнәрне гомумиләштереп кабатлау. | | |
| 60 | Алмашлык. | 1 | Алмашлыклар белән җөмләләр төзү. | Алмашлыкларны башка сүз төркемнәреннән аеру. | | |
| 61 | Зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше | 1 | | Зат алмашлыкла-рын сөйләмдә куллана белү. | | |
| 62 | Сорау алмаш лыклары. Аларның килеш белән төрләнүе | 1 | Алмашлыклар белән җөмләләр төзү. | Алмашлыкларны башка сүз төркемнәреннән аеру. Сорау алмашлыкларын сөйләмдә куллана белү. | | |
| 63 | Хәтер диктанты. | 1 | Хәтердән язу. | Хәтердән грамоталы язу | | |
| 64 | БСҮ №15 Котлау язу Алмашлыкларны гомумиләштереп кабатлау. | 2 | Котлау язу.Күнегүләр эшләү | Алмашлыклар темасы буенча белемнәрне системалаштыру | | |
| 65 | Фигыль. Фигыльнең барлык һәм юклык формасы. | 1 | Рәсемнәр буенча җөмләләр төзү, күнегүләр эшләү. | Фигыль турында белемнәрне барлау. | | |
| 66 | Фигыльнең заман белән төрләнүе | 1 | Күнегүләр эшләү, кагыйдәләр өйрәнү | Фигыльнең заман кушымчалары | | |
| 67 | БСҮ №16 Яз килә. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Яз килә. темасына хикәя төзү | | |
| 68 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 | Күнегүләр эшләү, төрләндерү | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | | |
| 69 | БСҮ №17 Минем дүрт аяклы дустым. Фигыльләрне кабатлау. | 1 | Рәсем буенча сорауларга җавап бирү,терәк сүзләр белән җөмләләр төзү. | Минем дүрт аяклы дустым темасына хикәя төзү | | |
| 70 | Сыйфат. | 1 | Уку, сыйфатларны табу. | Сыйфатларны башка сүз төркемнәреннән аеру. | | |
| 71 | Синоним сыйфатлар. | 1 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Синоним һәм антоним сыйфатларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес куллана белү. | | |
| 72 | Антоним сыйфатлар. | 1 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Синоним һәм антоним сыйфатларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес куллана | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | белү. | | |
| 73 | Сыйфатның исемне ачыклап килүе, җөмләдәге роле | 1 | Әңгәмә, сүзтезмәләр, җөмләләр төзү. | | | |
| 74 | БСҮ №17 Изложение №1"Туган җиребез" | 1 | Әңгәмә, сорауларга җавап бирү, язу. | Тел күнекмәләренә игътибарлы булырга, нәтиҗә ясарга һәм фикерне төгәл итеп язарга өйрәнү. | | |
| 75 | Сыйфатларны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Күнегүләр эшләү | Сыйфатларны сөйләмдә куллануны арттыру | | |
| 76 | Сан турында төшенчә. | 1 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Сан турында төшенчә бирү. Татар телендә саналмышның берлек санда кулланылуы. | | |
| 77 | Саналмыш. | 1 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Сан ачыклаган исемнең саналмыш булуы. | | |
| 78 | Саннарны сөйләмдә куллану. | 1 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Татар телендә саналмышның берлек санда кулланылуы. | | |
| 79 | Контроль диктант №3 | 1 | Ишетеп язу, биремнәр эшләү. | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | | |
| 80 | БСҮ №18 Язның бер көне ел туйдыра. | 1 | Бирелгән тема буенча диалог, хикәя төзү. | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен активлаштыру. Саннарны сөйләмдә куллану. | | |
| 81 | Морфология бүлеген гомумиләштереп кабатлау | 1 | Күнегүләр эшләү | Морфология бүлеге буенча белемнәрне системалаштыру | | |
| Синтаксис | | | | | | |
| 82 | Сүзтезмә һәм җөмлә. | 1 | Сүзтезмәләр, җөмләләр төзү. | Сүзтезмә һәм җөмләне аера белү. | 03.04 | |
| 83 | БСҮ №19 Урманда | 1 | Бирелгән тема буенча диалог, хикәя төзү. | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен активлаштыру. | 8.04 | |
| 84 | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. | 1 | Уку, тиешле тыныш билгеләрен куеп язу. | Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру. | 9.04 | |
| 85 | Хикәя җөмләләр. | 1 | Уку, тиешле тыныш билгеләрен куеп язу. | Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру. | 10.04 | |
| 86 | Сорау җөмләләр. | 1 | Уку, тиешле тыныш билгеләрен куеп язу. | Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру. | 15.04 | |
| 87 | Өндәү җөмләләр. | 1 | Күнегүләр эшләү, сүзлек эше | Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру. | 16.04 | |
| 88 | Раслау, инкарь җөмлә-ләр. Алар янында тыныш билгеләре | 1 | Күнегүләр эшләү, сүзлек эше | Раслау, инкарь җөмләләр янында тыныш билгеләренең кулланылышы | | |
| 89 | Инкарь итүнең төп формалары | 1 | Күнегүләр эшләү, җөмләләр төзү | Хәбәр булып килгән фигыльдә юклык кушымча-ларын, түгел кисәкчәсен, юк | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | хәбәрлек сүзен куллану | | |
| 90 | БСҮ №20Язгы өмәдә. | 1 | Бирелгән тема буенча диалог, хикәя төзү. | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен активлаштыру. | | |
| 91 | Сайланма диктант | 1 | Дөрес сайлап язу. | Белемнәрен тикшерү. | | |
| 92 | Хаталар өстендә эш. Җөмләнең баш кисәкләре. | 1 | Җөмләләрдән ия һәм хәбәрне табу. | Белемнәрне барлау, ныгыту. Татар телендә гадәттә иянең хәбәрдән алда килүе. | | |
| 93 | Җөмләнең иярчен кисәге. Аергыч. | 1 | Күчереп язу, аергычны табу. | Аергыч җөмләнең иярчен кисәге. Аергычның сыйфат белән белдерелүе. | | |
| 94 | Татар телендә җөмләдә сүз тәртибе. | 2 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Татар телендә җөмләдәге сүз тәртибен үзләштерү. | | |
| 95 | БСҮ №21 Яшелчә кибетендә. | 1 | Әңгәмә, сорауларга җавап бирү. | Яшелчә кибетендә темасы буенча сөйләшү. | | |
| 96 | БСҮ №22 Күчереп язу. | 1 | Күнегүләр эшләү. | Күчереп язу күнекмәсе | | |
| 97 | Җөмлә кисәкләре тема сын кабатлау | 1 | Күнегүләр эшләү. | Укучыларның белем һәм күнекмәләрен системалаштыру | | |
| 98 | Контроль диктант №4 | 1 | Ишетеп язу, биремнәр эшләү. | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | | |
| 99 | Хаталар өстендә эш.Кабатлау. | 1 | Күнегүләр эшләү. | Укучыларның белем һәм күнекмәләрен системалаштыру | | |
| Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | | | | | | |
| 100 | БСҮ №23 Җәй җитте! | 1 | Әңгәмә, сорауларга җавап бирү. | “Җәй җитте!” темасы буенча сөйләшү. | | |
| 101 | Ел буена үткәннәрне кабатлау | 1 | Күнегүләр эшләү | Хаталарны төзәтү. Укучыларның белем һәм күнекмәләрен системалаштыру | | |
| 102 | БСҮ №24 Музейда. | 1 | Әңгәмә, сорауларга җавап бирү. | Музейда темасы буенча сөйләшү | | |
| | Йомгаклау дәресе. | 1 | Төрле биремле күнегүләр эшләү. | Укучыларның белем һәм күнекмәләрен системалаштыру | | |

3 класс уку

# Әдәби уку дәресеннән эш программасы

# 3 нче сыйныф

# (102 сәг)

**Аңлатма язуы**

***Эш программасы статусы.***

.

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. "Мәгариф турында" Россия Федерациясенең Законы ("Закон об образовании" Закон Российской Федерации)

2. "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законы.

- 6 статья – белемалу теле (телләре)

- 7 статья– мәгарифнең дәүләт стандартлары

-10 статья –уку-укытупрограммалары

- 32 статья – мәгариф учреждениесенең вәкаләтләре һәм җаваплылыгы.

3."РФнең телләр турындагы" Законы (№126-ФЗ 24.07.1998)

4."ТР дәүләт телләре һәм ТРның башка телләр" Законы ( №443РТ, 18.07.2004)

5.ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 нче ел 9 нчы июль 4154 /12 номерлы "ТР гомуми һәм төп белем бирү оешмалары өчен базис һәм үрнәк укыту планнарын раслау турындагы" карары

6.Сан ПиН 2.4.2.2821-10. "Гомумбелем бирү оешмаларында укытуга карата санитар-эпидемиологик таләпләр" (РФ төп дәүләт санитар табибы карары белән 2010 нчы елның 29 нчы декабрендә расланган. РФ Юстиция Министрлыгы тарафыннан 2011 нче елның 3 нче марты 189 номеры белән теркәлгән, теркәлү номеры - 19993)

7. Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. (Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В.Х.Хаков, Г.Г.Измайлова, Э.Х.Хәмидуллина – Казан, 2008).

8. "Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы" (рус балалары өчен) 1-11 нче сыйныфлар. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән. (Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В.А.Гарипова, Р.Р.Җамалетдинов, Х.Г.Җамалетдинова-Казан,"Мәгариф"нәшрияты,2010)

9.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы 3нче санлы Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбенең 2014-2015уку елы өчен укыту планы ( протокол №1, 28 август 2014ел)

10. Дәреслек. Татар теле Татарский язык. Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 3нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телендә сөйләшүче балалар өчен). (Р.Х.Ягъфарова, К.С. Фәтхуллова: Казан, ТКН, 2013)

***Эш программасы структурасы*.**

Уку дәресеннән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.***

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Уку дәресләренең **максатлары:**

— уку күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү;

— укуга, китапка кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү;

— матур әдәбият, аның авторы, әсәрнең жанры, персонажы турында күзаллау булдыру;

— дөрес һәм бәйләнешле әйтмә һәм язма сөйләмгә өйрәтү;

— әдәби әсәрләр йогынтысында үз-үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре булдыру.

